**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2024 елның 22 ноябрендәге 4789 номерлы карары**

# Казан шәһәре Башкарма комитетының 2019 елның 30 декабрендәге 4694 номерлы «Казан шәһәре Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе карамагындагы аерым муниципаль оешмалар хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында»гы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Белем бирү учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләүнең оклад системасын кертү буенча чаралар планын гамәлгә ашыру максатыннан, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 елның 1 декабрендәге 998 номерлы «Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы һәм Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы карамагындагы аерым оешмалар хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турында»гы карарына таянып, **карар бирәм**:

1. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2019 елның 30 декабрендәге 4694 номерлы «Казан шәһәре Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе карамагындагы аерым муниципаль оешмалар хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турында»гы карарына (аңа Казан шәһәре Башкарма комитетының 2022 елның 5 июлендәге 2125 номерлы, 2023 елның 12 гыйнварындагы 33 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1, 2 номерлы кушымталарны гамәлдән чыккан дип танырга;

1.2. әлеге карарның 1, 2 номерлы кушымталарын Казан шәһәре Башкарма комитетының 2019 елның 30 декабрендәге 4694 номерлы карарының 1, 2 номерлы кушымталары дип санарга.

2. Әлеге карар белән раслана торган нигезләмәләр Казан шәһәренең аерым муниципаль белем бирү оешмалары хезмәткәрләре өчен 2024 елның 1 июленнән гамәлгә кертелә дип билгеләргә.

3. Казан шәһәренең аерым муниципаль оешмалары хезмәткәрләренең

әлеге карар нигезендә билгеләнә торган хезмәт хакы, хезмәткәрләрнең вазифаи бурычлары күләмен саклап калу һәм шул ук квалификациядәге эшләрне башкару шарты белән, хезмәт өчен түләүнең яңа шартларына күчү вакытына гамәлдә булган хезмәт өчен түләү системасы нигезендә түләнә торган хезмәт хакыннан кимрәк була алмый дип билгеләргә.

4. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары Г.Р.Сәгыйтовага йөкләргә.

**Җитәкче вазифаларын башкаручы –**
**беренче урынбасар** **А.Р.Нигъмәтҗанов**

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2024 елның 22 ноябрендәге
4789 номерлы карарына
1 номерлы кушымта

**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**Мәгариф идарәсе карамагындагы аерым муниципаль оешмалар хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турында нигезләмә**

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Казан шәһәре Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе карамагындагы аерым муниципаль оешмалар хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турындагы әлеге Нигезләмә (алга таба – Нигезләмә) хезмәткәрләрнең окладларын формалаштыру тәртибен, компенсация һәм кызыксындыру характерындагы түләүләрнең шартларын һәм күләмен, шулай ук аларны билгеләү критерийларын билгели.

1.2. 2. Әлеге Нигезләмәдә түбәндәге төшенчәләр һәм билгеләмәләр кулланыла:

- аерым белем бирү муниципаль оешмалары – Казан шәһәре Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе карамагындагы аерым муниципаль оешмалар: Казан шәһәренең «Мәгариф хезмәткәрләре йорты» муниципаль бюджет учреждениесе;

- хезмәткә түләү системасы – федераль законнар һәм Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары нигезендә билгеләнгән төп окладлар, хезмәт хакының төп ставкалары, вазифаи окладлар, шулай ук компенсация һәм кызыксындыру түләүләре күләмен дә кертеп, аерым муниципаль белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартларын һәм күләмен билгели торган нормалар җыелмасы;

- төп оклад – хезмәткәрнең календарь айда хезмәт (вазифаи) бурычларын үтәгән өчен яки, компенсация, кызыксындыру һәм социаль характердагы түләүләрне исәпкә алмыйча, башкарыла торган эшләрнең катлаулылыгына карап, хезмәт нормасы (хезмәт хакы ставкасы өчен атналык (еллык) педагогик эш нормасы) өчен билгеләнгән оклад;

- вазифаи оклад – кызыксындыру, компенсация характерындагы һәм социаль түләүләрне исәпкә алмыйча, бер календарь ай эчендә фактта эшләгән

вакыт аралыгында билгеле бер катлаулылыктагы хезмәт (вазифаи) бурычларын үтәгән өчен хезмәткәрнең хезмәте өчен түләүнең билгеләнгән күләме;

- хезмәт хакы (хезмәткәрнең хезмәте өчен түләү) – хезмәткәрнең квалификациясеннән, башкарыла торган эшнең катлаулылыгыннан, күләменнән, сыйфатыннан һәм шартларыннан чыгып, хезмәт өчен түләү, шулай ук компенсация һәм кызыксындыру характерындагы түләүләр;

- компенсация характерындагы түләүләр – компенсация характерындагы, шул исәптән нормага туры килмәгән шартларда эшләгән өчен өстәп һәм өстәмә түләүләр һәм компенсация характерындагы башка түләүләр;

- кызыксындыру характерындагы түләүләр – кызыксындыру характерындагы өстәп һәм өстәмә түләүләр, премияләр һәм башка кызыксындыру түләүләре.

1.3. Казан шәһәренең аерым муниципаль белем бирү оешмаларының мәгариф хезмәткәрләре, мәдәният, сәнгать һәм кинематография өлкәсендә эшләүче хезмәткәрләре (алга таба – мәгариф хезмәткәрләре, мәдәният хезмәткәрләре) вазифаларының һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең хезмәт хакы (хезмәте өчен түләү):

- вазифаи окладлардан;

- компенсация характерындагы түләүләрдән;

- кызыксындыру сыйфатындагы түләүләрдән тора.

1.4. Мәгариф хезмәткәренең, мәдәният хезмәткәренең еллык яки башка ялда булу вакытында, вакытлыча хезмәткә яраксызлык чорында, шулай ук уртача хезмәт хакы саклана торган башка чорларда профиль буенча эш стажы артуга, квалификация категориясе бирелүгә, мактаулы исем бирелүгә, ведомство буенча аерым хөрмәт билгеләре белән бүләкләнүгә бәйле рәвештә хезмәтенә түләү күләме үзгәрүгә хокукы барлыкка килсә, аның хезмәтенә түләү күләме күрсәтелгән чорлар тәмамланганнан соң үзгәртелә.

1.5. Аерым муниципаль белем бирү оешмалары җитәкчеләре:

- белем алу һәм педагогик эш стажы (белгечлек буенча, билгеле бер вазифада эшләү) турындагы документларның Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау һәм социаль үсеш министрлыгының 2010 елның 26 августындагы 761н номерлы «Җитәкчекләр, белгечләр һәм хезмәткәрләр вазифаларының бердәм квалификация белешмәлеген раслау турында, “Мәгариф хезмәткәрләре вазифаларының квалификация характеристикалары” бүлеге» әмере белән расланган таләпләргә туры килү-килмәвен тикшерәләр;

- ел саен хезмәткәрләр буенча тарификация исемлекләрен төзиләр һәм раслыйлар;

- хезмәткәрләрнең хезмәт хакы күләмен вакытында һәм дөрес билгеләү өчен җавап бирәләр.

## II. Казан шәһәренең аерым муниципаль оешмалары мәгариф хезмәткәрләренең, мәдәният хезмәткәрләренең төп окладларын билгеләү

2.1. Казан шәһәренең аерым муниципаль оешмалары мәгариф хезмәткәрләренең төп окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| **Квалификация дәрәҗәсе** | **Вазифа атамасы** | **Бер айга төп оклад күләме, сумнарда** |
|---|---|---|
| Беренче дәрәҗәдәге укыту-ярдәмче персонал вазифаларының һөнәри квалификация төркеме | | |
| Беренче | Уку-укыту часте секретаре | 19515 |
| Икенче дәрәҗәдәге укыту-ярдәмче персонал вазифаларының һөнәри квалификация төркеме | | |
| Беренче | Кече тәрбияче | 19625 |
| Педагогик хезмәткәрләр вазифаларының һөнәри квалификация төркеме | | |
| Беренче | Физик культура буенча инструктор | 20705 |
| | Музыка буенча җитәкче | |
| Икенче | Педагог-оештыручы | 20800 |
| | Социаль педагог | |
| Өченче | Тәрбияче | 20900 |
| | Педагог-психолог | |
| | Өлкән инструктор-методист | |
| | Методист | |
| Дүртенче | Өлкән методист | 21000 |
| | Тьютор (югары һәм өстәмә һөнәри белем бирү өлкәсендә эшләүче тьютордан тыш) | |
| | Укытучы-дефектолог | |
| | Укытучы-логопед (логопед) | |
| Структур бүлекчәләр җитәкчеләре вазифаларының һөнәри квалификация төркеме | | |
| Беренче | Структур бүлекчә [кабинет, лаборатория, бүлек, бүлекчә, сектор, уку-укыту һәм консультация пункты, уку-укыту (уку-укыту һәм җитештерү) остаханәсе һәм балаларга гомуми белем бирү программасын һәм өстәмә белем бирү буенча мәгариф программасын гамәлгә ашыра торган | 21050 |

| Квалификация дәрәҗәсе | Вазифа атамасы | Бер айга төп оклад күләме, сумнарда |
|---|---|---|
| | башка структур бүлекчәләр, белем бирү эшчәнлеген методик һәм мәгълүмати-технологик яктан тәэмин итү буенча дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыра торган оешма (икенче кваликация дәрәҗәсенә кертелгән структур бүлекчәләр җитәкчеләре вазифаларыннан тыш)] мөдире (башлыгы) | |

2.2. Казан шәһәренең аерым муниципаль оешмалары мәдәният хезмәткәрләренең төп окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Вазифа атамасы | Бер айга төп оклад күләме, сумнарда |
|---|---|
| «Урта звено мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазифалары» һөнәри квалификация төркеме | |
| Аккомпаниатор | 20862 |
| Түгәрәк, һәвәскәр берләшмә, кызыксынулар буенча клуб җитәкчесе | |
| «Әйдәүче звено мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазифалары» һөнәри квалификация төркеме | |
| Китапханәче | 21362 |
| Тавыш операторы | |
| «Мәдәният, сәнгать һәм кинематография оешмасының җитәкче составы вазифалары» һөнәри квалификация төркеме | |
| Сәнгать җитәкчесе | 22562 |
| Коллектив җитәкчесе | |

## III. Казан шәһәренең аерым муниципаль оешмалары мәгариф хезмәткәрләренең, мәдәният хезмәткәрләренең төп оклады өчен сәгатьләр нормасы

3.1. Эш вакыты озынлыгы (хезмәт хакы ставкасы өчен педагогик эш вакыты нормалары) Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының 2014 елның 22 декабрендәге 1601 номерлы «Педагогик хезмәткәрләрнең эш вакыты озынлыгы (хезмәт хакы ставкасы өчен педагогик эш сәгатьләре нормалары) турында һәм хезмәт килешүендә билгеләнә торган педагогик хезмәткәрләрнең укыту йөкләнешен билгеләү тәртибе турында»гы боерыгында

билгеләнгән.

3.2. Мәдәният хезмәткәрләренең эш вакыты озынлыгы Россия Федерациясенең Хезмәт кодексында билгеләнә.

## IV. Казан шәһәренең аерым муниципаль белем бирү оешмаларындагы мәгариф хезмәткәрләренең, мәдәният хезмәткәрләренең вазифаи окладларын формалаштыру тәртибе

Казан шәһәренең аерым муниципаль белем бирү оешмаларындагы мәгариф хезмәткәрләренең, мәдәният хезмәткәрләренең вазифаи окладлары (Od) түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$O_d = O_b \times \frac{H_{fk}}{H_N} + P,$$

монда:

$O_b$ – Казан шәһәре мәгариф оешмаларындагы мәгариф хезмәткәрләренең, мәдәният хезмәткәрләренең әлеге Нигезләмәнең II бүлеге нигезендә кабул ителә торган төп окладлары күләме;

$H_{fk}$ – Казан шәһәренең аерым муниципаль белем бирү оешмаларының мәгариф хезмәткәрләре, мәдәният хезмәткәрләре тарафыннан фактта эшләнгән сәгатьләр саны;

$H_N$ – Казан шәһәренең аерым муниципаль белем бирү оешмаларының мәгариф хезмәткәрләренең, мәдәният хезмәткәрләренең база оклады өчен әлеге Нигезләмәнең III бүлегендә билгеләнгән сәгатьләр нормасы;

P – китап продукциясе һәм вакытлы басмалар белән тәэмин итүгә 100 сум күләмендәге компенсация педагогик хезмәткәрләргә укыту йөкләнешенә пропорциональ рәвештә, әмма төп эш урыны буенча бер ставкадан артмый торган итеп билгеләнә.

## V. Кызыксындыру характерындагы түләүләр

5.1. Кызыксындыру характерындагы түләүләргә мәгариф хезмәткәрләрен, мәдәният хезмәткәрләрен сыйфатлы хезмәт нәтиҗәсенә кызыксындыруга, шулай ук башкарылган эш өчен бүләкләүгә юнәлдерелгән түләүләр керә.

Кызыксындыру сыйфатындагы түләүләр түбәндәгеләрне үз эченә ала:

- квалификация категориясе өчен түләүләр;

- мактаулы исемнәр һәм ведомство бүләкләре өчен түләүләр;

- профиль буенча эш стажы өчен түләүләр;

- премия һәм башка кызыксындыру түләүләре;

- башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен түләүләр.

5.2. Казан шәһәренең аерым муниципаль белем бирү оешмаларының мәгариф хезмәткәрләренә кызыксындыру характерындагы түләүләр күләме һәм аларны билгеләү тәртибе.

5.2.1. Квалификация категориясе ($B_{kk}$) өчен түләүләр мәгариф хезмәткәрләренә аларда гамәлдәге квалификация категориясе булган очракта квалификация категориясенең гамәлдә булу вакыты чикләрендә бирелә һәм түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_{kk} = O_d \times \frac{D_{kk}}{100\%},$$

монда:

$O_d$ – аерым белем бирү оешмаларының мәгариф хезмәткәрләренең вазифаи оклады;

$D_{kk}$ – квалификация категориясе өчен өстәмәләр күләме.

Квалификация категориясе өчен өстәмә түләүләр күләме 1 нче таблицада китерелгән.

1 нче таблица

**Квалификация категориясе өчен өстәмә түләүләр күләме**

| **Квалификация дәрәҗәсе** | **Квалификация категориясе** | **Өстәмә түләүләр күләме, процентларда** |
|---|---|---|
| Педагогик хезмәткәрләр вазифаларының һөнәри-квалификация төркеме | | |
| Беренче | Беренче | 5,0 |
| | Югары | 6,0 |
| Икенче | Беренче | 6,0 |
| | Югары | 8,0 |
| Өченче | Беренче | 6,5 |
| | Югары | 10,0 |
| Дүртенче | Беренче | 8,0 |
| | Югары | 12,0 |
| Вазифаларның һөнәри квалификация төркеме<br>Структур бүлекчәләр җитәкчеләре | | |
| Беренче | Беренче | 6,0 |
| | Югары | 8,0 |

Квалификация категориясе өчен түләүләр тиешле аттестация комиссиясе тарафыннан уңай карар кабул ителгән көннән билгеләнә (үзгәртелә).

5.2.2. Мактаулы исемнәр һәм ведомство бүләкләре ($B_{pz}$) булган өчен түләүләр беренче һәм икенче дәрәҗәләрдәге ярдәмче персонал, педагогик хезмәткәрләр һәм структур бүлекчәләр җитәкчеләре вазифаларының һөнәри квалификация төркемнәренә керүче мәгариф хезмәткәрләре вазифалары буенча бирелә һәм түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_{pz} = O_d \times \frac{D_{pz}}{100\%},$$

монда:

$O_d$ – аерым белем бирү оешмаларының мәгариф хезмәткәрләренең вазифаи оклады;

$D_{pz}$ – мактаулы исемнәр һәм ведомство бүләкләре булган өчен өстәмә түләүләр күләме.

Россия Федерациясенең мактаулы исемнәре, Совет Социалистик Республикалар Союзының мактаулы исемнәре, Совет Социалистик Республикалар Союзы составындагы союздаш республикаларның мактаулы исемнәре булган өчен өстәмә түләү күләме 7 процентны тәшкил итә.

Татарстан Республикасының мактаулы исемнәре, Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасының мактаулы исемнәре булган өчен өстәмә түләү күләме 6 процентны тәшкил итә.

Россия Федерациясенең ведомство бүләкләре, Россия Совет Федератив Социалистик Республикасының ведомство бүләкләре, Татарстан Республикасының ведомство бүләкләре, Совет Социалистик Республикалар Союзының ведомство бүләкләре, Совет Социалистик Республикалар Союзы составындагы союздаш республикаларның ведомство бүләкләре булган өчен өстәмә түләү күләме 4 процентны тәшкил итә.

Мактау грамотасына ия булган өчен өстәмә түләү күләме 2 процентны тәшкил итә. Мактау грамотасына ия булган өчен өстәмә түләү, Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгының (Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгы, Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгы) ведомство бүләкләре белән бүләкләү тәртибе нигезендә, Россия Федерациясе Мәгариф министры (Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министры, Россия Федерациясе Мәгариф министры) боерыгы белән бүләкләнә торган мәгариф өлкәсе хезмәткәрләренә билгеләнә.

«Мәгарифтәге казанышлары өчен» күкрәк билгесе булган өчен өстәмә

түләү күләме 2 процентны тәшкил итә. «Мәгарифтәге казанышлары өчен» күкрәк билгесенә ия булган өчен өстәмә түләү Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министры (Татарстан Республикасы мәгариф министры) әмере нигезендә билгеләнә.

Мәгариф хезмәткәрләренә тиешле түләүләр бирелә торган мактаулы исемнәр һәм ведомство бүләкләре исемлеге әлеге Нигезләмәнең 1 номерлы кушымтасында китерелгән.

Мактаулы исемнәр һәм ведомство бүләкләре булган өчен түләү күләмнәре мактаулы исем һәм ведомство бүләге бирелгән көннән билгеләнә. Ике һәм аннан да күбрәк мактаулы исемнәре һәм (яки) ике һәм аннан да күбрәк ведомство бүләкләре булган хезмәткәрләргә түләү хезмәткәр сайлаган нигезләрнең берсе буенча билгеләнә.

5.2.3. Профиль буенча эш стажы өчен түләүләр ($B_s$), профиль буенча эшләү дәвамлылыгына бәйле рәвештә, төркемнәрдән, һөнәри квалификация төркемнәреннән һәм квалификация дәрәҗәләреннән чыгып, стаж буенча билгеләнә һәм түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_s = O_d \times \frac{D_s}{100\%},$$

монда:

$O_d$ – аерым мәгариф һәм спорт оешмаларының мәгариф хезмәткәрләренең вазифаи оклады;

$D_s$ – профиль буенча эш стажы өчен өстәмәләр күләме.

Профиль буенча эш стажы өчен өстәмә түләү күләме 2 нче таблицада китерелгән.

2 нче таблица

**Профиль буенча эш стажы өчен өстәмә түләүләр күләме**

| Һөнәри квалификация төркеме атамасы | Квалификация дәрәҗәсе | Стаж буенча төркем | Өстәмә түләүләр күләме, процентларда |
|---|---|---|---|
| Икенче дәрәҗәдәге ярдәмче-укыту персоналы вазифалары | Беренче – икенче | 4 елдан 10 елга кадәр | 1,0 |
| | | 10 елдан 15 елга кадәр | 2,0 |
| | | 15 елдан артык | 3,0 |
| Педагогик хезмәткәрләр | Беренче – дүртенче | 2 елдан 6 елга кадәр | 2,0 |

| Һөнәри квалификация төркеме атамасы | Квалификация дәрәҗәсе | Стаж буенча төркем | Өстәмә түләүләр күләме, процентларда |
|---|---|---|---|
| вазифалары | | 6 елдан 10 елга кадәр | 3,0 |
| | | 10 елдан 15 елга кадәр | 3,5 |
| | | 15 елдан артык | 4,0 |
| Структур бүлекчәләр җитәкчеләре вазифалары | Беренче – өченче | 2 елдан 6 елга кадәр | 2,0 |
| | | 6 елдан 10 елга кадәр | 3,0 |
| | | 10 елдан 15 елга кадәр | 3,5 |
| | | 15 елдан артык | 4,0 |

Эш стажы үзгәргәндә профиль буенча эш стажы өчен түләү күләмен билгеләү (үзгәртү), стажны раслаучы документлар учреждениедә булса, эш стажы өчен түләү күләмен арттырырга хокук бирүче стажны тутырган көннән алып яки стажны раслаучы кирәкле документны тапшырган көннән алып башкарыла.

5.2.4. 3 нче таблица нигезендә мәгариф һәм башка оешмалардагы педагогик, җитәкче һәм методик эш педагогик эш стажына исәпләнә.

3 нче таблица

**Аларда эшләү вакыты мәгариф хезмәткәрләренең педагогик стажына кертелә торган оешмалар һәм вазифалар исемлеге**

| Оешманың исеме | Вазифа атамасы |
|---|---|
| Белем бирү оешмалары (шул исәптән югары белем бирүче мәгариф оешмалары, югары белем бирүче хәрби белем бирү оешмалары һәм хәрби һөнәри белем бирү оешмалары, өстәмә һөнәри белем бирү оешмалары (белгечләрнең квалификациясен күтәрү), медицина оешмалары һәм социаль хезмәт күрсәтү оешмалары (балалар йортлары, балалар шифаханәләре)] | Мәктәп укытучылары, укытучылар, дефектолог укытучылар, логопед укытучылар (логопедлар), (тормыш иминлеге нигезләрен, чакырылышка кадәрге әзерлекне укытучы) укытучы-оештыручылар, физик тәрбия җитәкчеләре, өлкән мастерлар, җитештерү буенча укыту мастерлары (шул исәптән транспорт чаралары йөртергә, авыл хуҗалыгы машиналарында эшләргә, язу машинкаларында эшләргә һәм башка оештыру техникасында эшләргә өйрәтүче), өлкән методистлар, методистлар, өлкән инструктор-методистлар, инструктор-методистлар (шул |

| | |
|---|---|
| | исәптән физик культура һәм спорт, туризм буенча), концертмейстерлар, музыка җитәкчеләре, өлкән тәрбиячеләр, тәрбиячеләр, сыйныф тәрбиячеләре, социаль педагоглар, педагог-психологлар, педагог-оештыручылар, өстәмә белем бирү педагоглары, өлкән тренер-укытучылар, тренер-укытучылар, өлкән вожатыйлар (пионервожатыйлар), физкультура буенча инструкторлар, хезмәт буенча инструкторлар, директорлар (башлыклар, мөдирләр), укыту, укыту-тәрбия, укыту-җитештерү, тәрбия, мәдәни-тәрбия эшләре, сәнәгать буенча укыту (эш), чит телләр укыту буенча, очуга әзерлеккә укыту буенча, гомуми белем бирүгә әзерлек, режим буенча директор (башлык, мөдир) урынбасарлары, укыту буенча мөдирләр, эшчәнлекләре белем (тәрбия) бирү, методик тәэмин итү процессы белән бәйле практика, укыту-консультация пунктлары, логопедия пунктлары, интернатлар, бүлекчәләр, бүлекләр, лабораторияләр, кабинетлар секцияләр, филиаллар, курслар һәм башка структур бүлекчәләр мөдирләре (башлыклары); режим буенча өлкән дежурныйлар, режим буенча дежурныйлар, аккомпаниаторлар, культоештыручылар, экскурсоводлар; профессор-укытучы составлары |
| Барлык исемнәрдәге методик (укыту-методик) оешмалар (нинди ведомство карамагында булуына бәйсез рәвештә) | Җитәкчеләр, аларның урынбасарлары, секторлар, кабинетлар, лабораторияләр, бүлек мөдирләре; эшчәнлекләре методик тәэмин итүгә бәйле фәнни хезмәткәрләр; өлкән методистлар, методистлар |
| Мәгариф белән идарә итү органнары һәм мәгариф оешмалары белән җитәкчелек итүче органнар (структур бүлекчәләр) | Җитәкчеләр, инспекторлык, методик вазифалар, инструкторлык, шулай ук башка белгеч вазифалары (икътисади, финанс, хуҗалык эшчәнлеге, төзелеш, тәэмин итү, эш башкару белән бәйле вазифаларда эшләүдән тыш) |
| Җитештерүдә кадрлар әзерләү һәм аларның квалификациясен күтәрү мәсьәләләре белән шөгыльләнүче оешмаларның, республика башкарма хакимият органнары бүлекчәләренең кадрлар бүлекләре, техник белем бирү бүлекләре (бюросы) | Эшчәнлекләре әзерлек һәм квалификация күтәрү мәсьәләләре белән бәйле штаттагы укытучылар, сәнәгатьтә эшчеләрне производствога укыту мастерлары, җитәкче, методик вазифалар, инспектор, инженер вазифалары |
| Россия оборона спорт-техник | Җитәкче, команда-очу, команда-инструкторлар, |

| | |
|---|---|
| оешмасының һәм гражданнар авиациясенең белем бирү оешмалары | инженер-инструкторлар, инструкторлар һәм укытучылар составы, җитештерүгә укыту мастерлары, борт инженер-инструкторлары, очуга әзерләү буенча методистлар (борт инженерлары, борт операторлары, борт радистлары, икенче пилотлар, һава суднолары командирлары, штурманнар) |
| Предприятиеләрнең һәм оешмаларның тулай тораклары, торак-эксплуатация оешмалары, яшьләр торак комплекслары, балалар кинотеатрлары, яшь тамашачы театрлары, курчак театрлары, мәдәни-белем бирү оешмалары һәм балалар һәм яшүсмерләр белән эшләү предприятиеләренең һәм оешмаларының бүлекчәләре | Тәрбиячеләр, педагог-оештыручылар, педагог-психологлар (психологлар), укытучылар, балалар һәм яшүсмерләр өчен өстәмә белем бирү педагоглары (түгәрәк җитәкчеләре), балалар һәм яшүсмерләр белән эшли торган инструкторлар һәм инструктор-методистлар, тренер-укытучылар һәм башка белгечләр, балалар бүлекләре, секторлары мөдирләре |
| Төзәтү колонияләре, тәрбия колонияләре, тикшерү изоляторлары һәм төрмәләр, дәвалау-төзәтү оешмалары | Педагогик белеме булган очракта, түбәндәге вазифаларда эшләү (хезмәт итү): тәрбия эшләре буенча җитәкче урынбасары, отряд башлыгы, өлкән инспектор, гомуми белем бирү эше (укыту) буенча инспектор, өлкән инспектор-методист һәм инспектор-методист, җитештерү-техник белем бирү буенча өлкән инженер һәм инженер, җитештерү буенча өлкән мастер һәм мастер, саклау һәм режим буенча өлкән инспектор, укыту-техник кабинет мөдире, психолог |

**Искәрмә.**

Педагогик эш стажына түбәндәгеләр керә:

- өлкәннәргә социаль хезмәт күрсәтә торган медицина оешмаларында һәм оешмалардагы укытучы-дефектологлар, логопедлар, тәрбиячеләр, Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау оешмаларының оештыру-методик бүлеге методистлары сыйфатында эшләү вакыты;

- башка оешмаларда эшләү, Совет Социалистик Республикалар Союзы һәм Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә хезмәт итү, югары белем бирә торган мәгариф оешмаларында һәм урта буын белгечләрен әзерләү программалары буенча һөнәри белем бирү оешмаларында укыту вакыты, түбәндәге тәртиптә:

- педагогик хезмәткәрләрнең педагогик эш стажына бернинди шартларсыз һәм чикләүләрсез кушыла:

- контракт буенча хәрби хезмәттә булу вакытында хәрби хезмәттәге бер

көн бер эш көне өчен булган исәптән, ә чакырылыш буенча хәрби хезмәттә булу вакыты хәрби хезмәттәге бер көн ике эш көне исәбеннән;

- фильмотека мөдире һәм фильмотека методисты вазифасында эшләү вакыты;

- педагогик хезмәткәрләрнең педагогик эш стажына, аерым алганда да, тулаем алганда да әлеге чорлар алдыннан һәм алардан соң педагогик эшчәнлек алып барылган очракта, түбәндәге вакыт чорлары керә:

- контракт буенча һәм чакырылыш буенча хәрби хезмәттә булу вакытыннан тыш, Совет Социалистик Республикалар Союзы һәм Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә офицер, сержант, составларның, прапорщикларның һәм мичманнарның старшинасы вазифаларында (шул исәптән Эчке эшләр министрлыгы гаскәрләрендә, куркынычсызлык гаскәрләрендә һәм органнарында) хезмәт итү вакыты;

- Россия Федерациясе халык мәгарифе һәм фән хезмәткәрләре (белем бирү, югары мәктәп һәм фәнни оешмалар) профсоюзының территориаль оешмалары (комитетлары, советлары) аппаратларында җитәкче, инспектор, инструктор һәм башка белгечлек вазифаларында; профсоюз органнарында сайлап куела торган вазифаларда; балалар фондының педагогик җәмгыятьләрендә һәм идарәләрендә инструктор һәм методист вазифаларында; Укытучылар йорты директоры (мөдире) (халык мәгарифе, һөнәри-техник белем бирү хезмәткәре) вазифасында; балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссияләре яки балигъ булмаганнарны социаль-хокукый саклау бүлекләрендә, эчке эшләр органнарының хокук бозуларны кисәтү бүлекчәләрендә (балигъ булмаганнар эшләре буенча инспекцияләрдә, милициянең балалар бүлмәләрендә) эшләү вакыты.

5.2.5. Педагогик хезмәткәрләрнең аерым категорияләренең педагогик эш стажына белем бирү оешмасындагы эш профиленә яки укыту предметы (курс, дисциплина, түгәрәк) профиленә туры килә торган белгечлек (һөнәр) буенча оешмаларда эшләү вакыты һәм Совет Социалистик Республикалар Союзы һәм Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә хезмәт итү вакыты керә:

- укытучы-оештыручыларга (тормыш иминлеге нигезләре, хәрби хезмәткә кадәрге әзерлек);

- физик тәрбия буенча мәктәп укытучыларына һәм укытучыларга, физик тәрбия җитәкчеләренә, физкультура инструкторларына, инструктор-методистларга (өлкән инструктор-методистларга), тренер-укытучыларга (өлкән тренерлар-укытучыларга);

- хезмәткә (һөнәри) өйрәтү, технология, сызым, рәсем сәнгате,

информатика, махсус дисциплиналар, шул исәптән аерым фәннәрне тирәнтен өйрәтүче гомуми белем бирү оешмаларының (сыйныфларының) махсус дисциплиналары укытучыларына, мәктәп укытучыларына;

- өстәмә белем бирү педагогларына;
- эксперименталь белем бирү оешмаларының педагогик хезмәткәрләренә;
- педагог-психологларга;
- методистларга;
- музыка һәм сәнгать буенча гомуми белем бирү оешмаларының махсус дисциплиналары укытучыларына.

5.2.6. Мәктәпкәчә белем бирү оешмалары, сабыйлар йортлары тәрбиячеләренең (өлкән тәрбиячеләренең) педагогик стажына мәктәпкәчә белем бирү оешмаларының ясле төркеме шәфкать туташы, сабыйлар йортларының посттагы шәфкать туташы вазифаларында эшләү вакыты, ә ясле төркемнәре тәрбиячеләренә – медицина вазифаларында эшләү вакыты кертелә.

Тәрбияче ярдәмчесе һәм кече тәрбияче вазифаларында эшләү вакыты, әлеге вазифаларда эшләү чорында хезмәткәрнең педагогик белеме булса яки югары белем яки һөнәри белем бирү оешмасында укыса, педагогик эш стажына исәпләнә.

Оешма хезмәткәрләренең белем бирү оешмаларында төп эшеннән тыш башкарылган педагогик эш вакыты, сәгатьләп түләү шартларында аның күләме уку елында 180 сәгатьтән дә ким булмаса, педагогик стажга кертелә.

Шул ук вакытта педагогик стажга педагогик эш башкарган айлар гына кертелә.

Оешмаларда эшнең һәм Совет Социалистик Республикалар Союзы Кораллы Көчләрендә һәм Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә хезмәтнең укыту предметы (курс, дисциплина, түгәрәк) эш профиленә туры килүе турындагы конкрет мәсьәләләрне хәл итү хокукы, профсоюз органы белән килештереп, мәгариф оешмасы җитәкчесенә бирелә.

5.3. Аерым муниципаль белем бирү оешмаларының мәдәният хезмәткәрләренә кызыксындыру характерындагы түләүләр күләме һәм аларны билгеләү тәртибе.

5.3.1. Квалификация категориясе өчен түләүләр ($B_{kk}$) , һөнәри квалификация төркемнәреннән чыгып, аттестация йомгаклары буенча тариф-квалификация характеристикалары нигезендә квалификация категорияләре бирүне күз алдында тота торган белгечлекләр буенча эшләүче аерым муниципаль мәгариф оешмаларының мәдәният хезмәткәрләренә бирелә.

$$B_{kk} = O_d \times \frac{D_{kk}}{100\%},$$

монда:

$O_d$ - аерым муниципаль мәгариф оешмаларындагы мәдәният хезмәткәрләренең вазифаи оклады;

$D_{kk}$ - квалификация категориясе өчен өстәмә түләүләр күләме.

Квалификация категориясе өчен өстәмә түләү күләмнәре 4 нче таблицада китерелгән.

Квалификация категориясе өчен түләүләрне үзгәртү (билгеләү) аттестация комиссиясе төзелгән орган (оешма) әмере датасы нигезендә башкарыла.

4 нче таблица

**Квалификация категориясе өчен өстәмә түләүләр күләме**

| **Квалификация категориясе** | **Өстәмә түләүләр күләме, процентларда** |
|---|---|
| «Әйдәүче звено мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазифалары» һөнәри квалификация төркеме | |
| Беренче | 5,0 |
| Югары | 8,0 |

5.3.2. Мактаулы исемнәр һәм ведомство бүләкләре булган өчен түләү ($B_{pz}$) мәгариф хезмәткәрләренә бирелә һәм түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_{pz} = O_d \times \frac{D_{pz}}{100\%},$$

монда:

$O_d$ – аерым муниципаль мәгариф оешмаларындагы мәдәният хезмәткәрләренең вазифаи оклады;

$D_{pz}$ – мактаулы исемнәр һәм ведомство бүләкләре булган өчен өстәмә түләү күләме.

Татарстан Республикасының, Совет Социалистик Республикалар Союзы составындагы автономияле республикаларның дәүләт бүләкләренә ия булган өчен өстәмә түләү күләме алты процентны тәшкил итә.

Россия Федерациясе, Совет Социалистик Республикалар Союзы, Совет Социалистик Республикалар Союзы составындагы союз республикаларның дәүләт бүләкләренә ия булган өчен өстәмә түләү күләме җиде процентны тәшкил

итә.

Мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләренә тиешле түләүләр бирелә торган мактаулы исемнәр исемлеге әлеге Нигезләмәнең 2 номерлы кушымтасында китерелгән.

Мактаулы исемнәр һәм дәүләт бүләкләренә ия булган өчен түләү күләмнәре мактаулы исем һәм дәүләт бүләге бирелгән көннән билгеләнә. Ике һәм аннан да күбрәк мактаулы исемнәре һәм (яки) ике һәм аннан да күбрәк ведомство бүләкләре булган хезмәткәрләргә түләү хезмәткәр сайлаган нигезләрнең берсе буенча билгеләнә.

5.3.3. Профиль ($B_s$) буенча эш стажы өчен түләүләр, хезмәткәрләр эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү индикаторларын үтәүне исәпкә алып, профиль буенча эш дәвамлылыгына карап, һөнәри-квалификация төркемнәре киселешендә аерым муниципаль мәгариф оешмаларының мәдәният хезмәткәрләренә билгеләнә һәм түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_s = O_d \times \frac{D_s}{100\%},$$

монда:

$O_d$ – аерым муниципаль мәгариф оешмаларындагы мәдәният хезмәткәрләренең вазифаи оклады;

$D_s$ – профиль буенча эш стажы өчен өстәмә түләү күләме.

Профиль буенча стаж өчен өстәмә түләүләр күләме 5 нче таблицада китерелгән.

5 нче таблица

**Профиль буенча эш стажы өчен өстәмә түләүләр күләме**

| **Һөнәри квалификация төркеме исеме** | **Стаж буенча төркем** | **Өстәмә түләүләр күләме, процентларда** |
|---|---|---|
| Урта звено мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазифаларының һөнәри квалификация төркеме | 3 елдан 6 елга кадәр | 1,0 |
| | 6 елдан 10 елга кадәр | 1,5 |
| | 10 елдан 15 елга кадәр | 2,0 |
| | 15 елдан артык | 2,5 |
| Әйдәүче звено мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазифаларының һөнәри квалификация төркеме | 3 елдан 6 елга кадәр | 1,0 |
| | 6 елдан 10 елга кадәр | 2,5 |
| | 10 елдан 15 елга кадәр | 3,5 |
| | 15 елдан артык | 4,0 |

Эш стажы үзгәргәндә профиль буенча эш стажы өчен түләүләр күләме, әгәр стажны раслый торган документлар оешмада булса, профиль буенча эш стажы өчен түләүләр күләмен арттыру хокукын бирә торган стажга ирешкән көннән алып яисә стажны раслый торган кирәкле документ тапшырылган көннән алып билгеләнә (үзгәртелә).

5.3.4. Премия һәм башка бүләкләү түләүләре төп эш урыны һәм төп вазифасы буенча аерым муниципаль мәгариф оешмаларының мәгариф хезмәткәрләренә, мәдәният хезмәткәрләренә (дефектолог укытучы, логопед укытучы [логопед] вазифасын били торган хезмәткәрләрдән тыш) юбилей даталарына, аерымлык билгеләре, рәхмәт хатлары, дәүләт бүләкләре алуга бәйле рәвештә һәм оешманың локаль актлары һәм коллектив шартнамәләре белән билгеләнгән башка нигезләрдә билгеле бер вакыт аралыгы өчен бер тапкыр билгеләнә.

Эш нәтиҗәләре буенча премия һәм башка бүләкләү түләүләрен башкару күләме, тәртибе һәм шартлары оешмаларның локаль актлары һәм коллектив килешүләр белән билгеләнә.

Аерым муниципаль мәгариф оешмалары хезмәткәрләренә премия түләүләренә каралган хезмәт өчен түләү фонды күләме хезмәт хакын (вазифаи окладларны) түләү өчен каралган хезмәт өчен түләү фондының, кызыксындыру характерындагы түләүнең, фән, методик яисә цикл комиссиясе, методик берләшмәләр белән җитәкчелек иткән өчен, уку кабинетлары, лабораторияләр, музейлар белән мөдирлек иткән өчен, төп эш урыны һәм төп вазифа буенча хезмәткәрләргә («укытучы дефектолог», «укытучы логопед (логопед)» вазифасын били торган хезмәткәрләрдән тыш) эшчәнлек үзенчәлекләре өчен түләүләрнең кимендә ике процентын тәшкил итә.

5.4. Башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен түләүләр, аерым муниципаль мәгариф оешмаларының мәгариф хезмәткәрләренә, мәдәният хезмәткәрләренә төп эш урыны буенча (дефектолог укытучы, логопед укытучы (логопед) вазифаларын биләүче хезмәткәрләрдән тыш) билгеле бер вакыт аралыгындагы хезмәт нәтиҗәләре буенча билгеләнә. Башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен түләүләрнең күләменә йогынты ясый торган төп критерий булып аерым муниципаль мәгариф оешмаларындагы мәгариф хезмәткәрләренең, мәдәният хезмәткәрләренең эшчәнлек нәтиҗәлелеген бәяләү критерийларының иң чик күрсәткечләренә ирешү тора.

Аерым муниципаль мәгариф оешмаларындагы мәгариф хезмәткәрләре, мәдәният хезмәткәрләре эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү критерийлары

оешма белән идарә итүнең дәүләт-иҗтимагый характерын тәэмин итүче орган белән килештереп, оешма җитәкчесе тарафыннан раслана. Аерым муниципаль мәгариф оешмаларындагы мәгариф хезмәткәрләре, мәдәният хезмәткәрләре эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү критерийлары күрсәткечләре, түләүләрне башкару шартлары, оешма алдына куелган бурычлар нигезендә, ел саен билгеләнә.

5.4.1. Башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен аерым муниципаль мәгариф оешмаларындагы мәгариф хезмәткәрләренә, мәдәният хезмәткәрләренә түләүләр күләме, тәртибе һәм шартлары оешманың локаль норматив актлары һәм коллектив килешүләр белән билгеләнә.

5.4.2. Башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен түләүләр түбәндәге формула буенча исәпләнә: $B_{kj}$

$$B_{kj} = \frac{FOT_k}{\sum_{i=1}^{n} \sum_{j=1}^{m} \left( I_{ij} \times K_i \right)} \times \sum_{i=1}^{n} \left( I_{ij} \times K_i \right),$$

монда:

$FOT_k$ – башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен түләүгә каралган хезмәт өчен түләү фонды;

$I_{ij}$ – j хезмәткәр буенча эшчәнлекнең нәтиҗәлелеген бәяләүнең нормалаштырылган i критерие;

$K_i$ – эшчәнлек нәтиҗәлелеген бәяләүдәге i критерийның чагыштырма авырлык коэффициенты;

n – эшчәнлек нәтиҗәлелеген бәяләү критерийлары саны;

m – аерым муниципаль мәгариф оешмалары хезмәткәрләре саны.

5.4.3. Эшчәнлек нәтиҗәлелеге критерийларын нормалаштыру төрле зурлыктагы нәтиҗәлелек критерийларын чагыштыруны тәэмин итә. Нормалаштыру эшчәнлек нәтиҗәлелеге критерие күрсәткечләре диапазонын (иң яхшысын һәм иң начарын) сайлаудан гыйбарәт, шуларның берсе нормалаштырылган критерийның нульгә тигезләнгән күрсәткеченә, башкасы – бергә тигезләнгән күрсәткеченә туры килә. Нәтиҗәлелек критериенең факттагы күрсәткече эшчәнлек нәтиҗәлелеге критерие күрсәткече диапазоны чикләрендә булганда, эшчәнлек нәтиҗәлелегенең нормалаштырылган критерие нульдән алып бергә кадәр билгеләнә. Нәтиҗәлелек критериенең факттагы күрсәткече иң

начар күрсәткечтән түбәнрәк булганда нормалаштырылган критерий күрсәткече – нульгә, иң яхшы билгедән югары булганда бергә тигез була.

5.4.4. Эшчәнлек нәтиҗәлелегенең нормалаштырылган критерий күрсәткеченең эшчәнлек нәтиҗәлелеге критерие күрсәткеченә бәйле булуы турыдан-туры (уңай динамика критерий күрсәткече арту белән билгеләнә) һәм кире (уңай динамика критерий күрсәткече кимү белән билгеләнә) булырга мөмкин.

5.4.5. Нормалаштырылган критерий, аның күрсәткече критерий күрсәткеченә ($I_i$) турыдан-туры бәйле булганда, түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$I_i = \frac{FI_i - L_i}{M_i - L_i},$$

монда:

$FI_i$ – эшчәнлек нәтиҗәлелеге критериеның фактагы күрсәткече;

$M_i$ – эшчәнлек нәтиҗәлелеге критериеның иң яхшы күрсәткече;

$L_i$ – эшчәнлек нәтиҗәлелеге критериеның иң начар күрсәткече.

5.4.6. Эшчәнлек нәтиҗәлелегенең нормалаштырылган критерие, аның күрсәткече критерий күрсәткеченнән ($I_i$) турыдан-туры бәйле булмаганда, түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$I_i = 1 - \frac{FI_i - L_i}{L_i - M_i},$$

монда:

$FI_i$ – эшчәнлек нәтиҗәлелеге критериеның фактагы күрсәткече;

$M_i$ – эшчәнлек нәтиҗәлелеге критериеның иң яхшы күрсәткече;

$L_i$ – эшчәнлек нәтиҗәлелеге критериеның иң начар күрсәткече.

5.4.7. Үлчәү коэффициентлары белән эшчәнлек нәтиҗәлелеге критериенең өстенлек дәрәҗәсе билгеләнә. Иң өстенлекле критерийга иң зур коэффициент бирелә. Чагыштырма үлчәү коэффициенты ($K_i$) түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$K_i = \frac{VK_i}{\sum_{i=1}^{n} VK_i}$$

,

монда:

$VK_i$ – эшчәнлек нәтиҗәлелеген бәяләү критериенең i үлчәү коэффициенты;

5.4.8. Аерым мәгариф оешмалары хезмәткәрләре эшчәнлегенең нәтиҗәлелеге критерийлары буенча авырлык коэффициентларының иң чик гомуми күләме 6 һәм 7 нче таблицаларда китерелгән.

6 нчы таблица

**Мәгариф хезмәткәрләре эшчәнлегенең нәтиҗәлелеге критерийлары буенча үлчәү коэффициентларының иң югары җыелма күләме**

| № т/б | Вазифа атамасы | Үлчәү коэффициентларының иң чик җыелма күләме |
|---|---|---|
| 1. Беренче дәрәҗәдәге ярдәмче укыту персоналының һөнәри-квалификация төркеме | | |
| 1.1 | Уку-укыту часте секретаре | 5 |
| 2. Икенче дәрәҗәдәге ярдәмче укыту персоналының һөнәри-квалификация төркеме | | |
| 2.1 | Кече тәрбияче | 35 |
| 3. Педагогик хезмәткәр вазифаларының һөнәри квалификация төркеме | | |
| 3.1 | Физик культура буенча инструктор | 45 |
| 3.2 | Музыка буенча җитәкче | 45 |
| 3.3 | Педагог-оештыручы | 50 |
| 3.4 | Социаль педагог | 50 |
| 3.5 | Тәрбияче | 55 |
| 3.6 | Методист | 55 |
| 3.7 | Педагог-психолог | 55 |
| 3.8 | Өлкән инструктор-методист | 55 |
| 3.9 | Өлкән методист | 60 |
| 3.10 | Тьютор (югары һәм өстәмә һөнәри белем бирү өлкәсендә эшләүче тьютордан тыш) | 60 |
| 3.11 | Укытучы-дефектолог | 60 |
| 3.12 | Укытучы-логопед (логопед) | 60 |
| 4. Структур бүлекчә җитәкчеләре вазифаларының һөнәри квалификация төркеме | | |
| 4.1 | Структур бүлек мөдире (башлыгы): кабинет, лаборатория, бүлек, бүлекчә, сектор, укыту-консультация пункты, укыту | 65 |

| № т/б | Вазифа атамасы | Үлчәү коэффициентларының иң чик җыелма күләме |
|---|---|---|
| | (укыту-җитештерү) остаханәсе һәм балаларга гомуми белем бирү программасын һәм өстәмә белем бирү программасын гамәлгә ашыра торган башка структур бүлекчәләр (икенче квалификация дәрәҗәсенә кертелгән структур бүлекчәләр җитәкчеләреннән тыш) | |

7 нче таблица

**Мәдәният хезмәткәрләре эшчәнлегенең нәтиҗәлелеге критерийлары буенча авырлык коэффициентларының иң югары җыелма күләме**

| № т/б | Вазифа атамасы | Үлчәү коэффициентларының иң чик җыелма күләме |
|---|---|---|
| 1. Урта звено мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазифаларының һөнәри квалификация төркеме . | | |
| 1.1 | Аккомпаниатор | 35 |
| 1.2 | Мәдәни чаралар оештыручы | 35 |
| 1.3 | Түгәрәк, коллектив, һәвәскәр берләшмә җитәкчесе, кызыксыну буенча клуб | 35 |
| 2. Алдынгы звено мәдәният хезмәткәрләре вазифаларының һөнәри квалификация төркеме | | |
| 2.1 | Китапханәче | 40 |
| 2.2 | Тавыш операторы | 40 |

5.4.9. Аерым муниципаль мәгариф оешмаларының мәгариф хезмәткәрләре, мәдәният хезмәткәрләре эшчәнлегенең нәтиҗәлелек буенча типлаштырылган критерийлары, аларның авырлык коэффициентлары оешма җитәкчесе тарафыннан раслана.

5.4.10. Аерым муниципаль мәгариф оешмаларында башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен кызыксындыру сыйфатындагы түләүләр фонды ($FOT_k$) төзелә, аның күләме түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$FOT_k = FOT_{do} \times \frac{D_k}{100\%},$$

монда:

$FOT_{do}$ – аерым муниципаль мәгариф оешмаларының мәгариф

хезмәткәрләренең, мәдәният хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү фонды, төп эш урыны буенча (укытучы-дефектолог, укытучы-логопед [логопед] вазифаларын биләгән хезмәткәрләрдән кала) оклад (оклад, хезмәт хакы ставкалары) буенча;

$D_k$ – башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен кызыксындыру сыйфатындагы түләүләргә хезмәт өчен түләү фонды күләме.

Башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен кызыксындыру сыйфатындагы түләүләргә хезмәт өчен түләү фондының тәкъдим ителә торган күләме төп эш урыны (укытучы-дефектолог, укытучы-логопед (логопед) вазифасын биләүче хезмәткәрләрдән тыш) буенча хезмәткәрләрнең вазифаи окладлары (окладлары, хезмәт хакы ставкалары) буенча аерым муниципаль мәгариф оешмалары хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү фондының биш проценты күләмендә кабул ителә.

## VI. Компенсация сыйфатындагы түләүләр

6.1. Аерым муниципаль мәгариф оешмаларындагы мәгариф хезмәткәрләренең, мәдәният хезмәткәрләренә компенсация сыйфатындагы түләүгә түбәндәгеләр керә:

- предметлы, методик яисә цикллы комиссияләр, методик берләшмәләр җитәкчелеге өчен компенсация сыйфатындагы түләүләр;
- уку кабинетлары, лабораторияләр, музейлар мөдирлеге өчен компенсация сыйфатындагы түләүләр;
- эшчәнлекнең үзенчәлеге өчен компенсация сыйфатындагы түләүләр;
- зарарлы һәм (яки) куркыныч хезмәт шартлары булган эшләрдә эшләүче хезмәткәрләргә түләүләр;
- нормаль шартларга туры килмәгән шартларда (төрле квалификация буенча эшләр башкарганда, һөнәрләрне (вазифаларны) берләштергәндә, эш сәгатеннән тыш эшләгән өчен, төнлә эшләгән өчен һәм нормаль шартларга туры килмәгән башка шартларда эшләр башкарганда) эшләгән өчен компенсация характерындагы түләүләр.

6.2. Компенсация сыйфатындагы түләүләр, аларны гамәлгә ашыру күләмнәре һәм шартлары хезмәт законнары һәм хезмәт хокукы нормалары булган башка норматив хокукый актлар нигезендә күмәк килешүләр, локаль норматив актлар, хезмәт килешүе белән билгеләнә.

6.3. Предметлы, методик яки цикллы комиссияләр, методик берләшмәләр ($B_{nz}^{rk}$) белән җитәкчелек иткән өчен компенсация сыйфатындагы түләүләр

түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_{nz}^{rk} = O_b \times \frac{D_{rk}}{100\%}$$ ,

монда:

$O_b$ – әлеге Нигезләмәнең II бүлеге нигезендә кабул ителә торган аерым мәгариф һәм спорт оешмаларының педагогик хезмәткәрләренең база оклады күләме;

$D_{rk}$ – предмет, методик яки цикллы комиссияләр, методик берләшмәләр белән җитәкчелек иткән өчен өстәмәләр күләме 3 процент тәшкил итә.

Берничә комиссиянең, берләшмәнең җитәкчеләрен педагогик хезмәткәре белән тәэмин иткәндә түләүләр күләме һәр комиссия, берләшмә буенча түләүләр суммасы буларак исәпләнә.

6.4. Аерым мәгариф оешмаларының уку кабинетлары, лабораторияләре, музейлары белән мөдирлек иткән өчен компенсация сыйфатындагы түләү 444 сум тәшкил итә.

Кабинетлар, лабораторияләр белән мөдирлек итү, кабинет белем бирү процессын җиһазландыру буенча расланган таләпләрнең кимендә 50 проценты дәрәҗәсендә җиһазландырылганда, булган укыту-методик, дидактик һәм күрсәтмә материалның укыту кабинеты паспорты таләпләренә туры килү дәрәҗәсе белән билгеләнә.

Берничә уку кабинетының, лабораториянең, музейларның эшен педагогик хезмәткәрләр белән тәэмин иткәндә күрсәтелгән эшне тәэмин иткән өчен түләүләр күләме һәр уку кабинеты, лаборатория, музей буенча түләүләр суммасы буларак исәпләнә.

6.5. Зарарлы һәм (яисә) куркыныч хезмәт шартлары булган эшләрдә эшләүче хезмәткәрләргә, шулай ук нормадан тайпылган шартларда эшләгәнгә (төрле квалификациядәге эшләрне башкарганда, өстәмә һөнәрләр (вазифалар) башкарганда, эш сәгатеннән тыш эшләгәндә, төнлә эшләгәндә һәм нормаль булмаган башка шартларда эшләр башкарганда) компенсация сыйфатындагы түләүләр ($B_{kh}$) түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_{kh} = O_d \times \frac{D_{kh}}{100\%} \times \frac{H_{fk}}{H_N}$$ ,

монда:

$O_d$ – аерым муниципаль мәгариф оешмаларындагы мәгариф хезмәткәрләренең, мәдәният хезмәткәрләренең әлеге Нигезләмәнең II бүлеге

нигезендә кабул ителә торган төп окладлары күләме;

$D_{kh}$ – Россия Федерациясе Хезмәт кодексы нигезендә билгеләнә торган компенсация сыйфатындагы түләүгә өстәмә түләү күләме;

$H_{fk}$ – законнар белән компенсация характерындагы түләүләр карала торган факт буенча эшләнгән вакыт;

$H_{N}$ – аерым муниципаль мәгариф һәм мәдәният оешмаларының мәгариф хезмәткәрләренең, мәдәният хезмәткәрләренең база оклады (хезмәт хакы ставкасы) өчен әлеге Нигезләмәнең III бүлегендә билгеләнгән сәгатьләр нормасы.

Зарарлы һәм (яки) куркыныч хезмәт шартлары булган эшләрдә эшләүче хезмәткәрләр хезмәтенә түләү нормаль хезмәт шартларында төрле эшләр өчен билгеләнгән хезмәт хакы окладлары (вазифаи окладлар), ставкалары белән чагыштырганда зуррак күләмдә, хезмәт шартларын махсус бәяләү нигезендә вазифаи окладның дүрт проценты күләмендә билгеләнә.

6.6. Нормаль шартларга туры килмәгән шартларда эшләгән өчен (төрле квалификация буенча эшләр башкарганда, һөнәрләрне (вазифаларны) берләштергәндә, эш сәгатеннән тыш эшләгән өчен, төнлә эшләгән өчен һәм нормаль шартларга туры килмәгән башка шартларда эшләр башкарганда) эш өчен түләүләр Россия Федерациясе Хезмәт кодексы нигезендә билгеләнә.

6.7. Әлеге оешмада, бүлекчәдә һәм вазифада эшнең конкрет шартларын исәпкә алып, компенсация характерындагы өстәмәләр билгеләнә торган вазифалар исемлеге сайлап куела торган профсоюз органы яисә мәгариф һәм мәдәният хезмәткәрләре мәнфәгатьләрен яклау вәкаләте булган орган белән килештереп, һәр оешмада раслана.

## VII. Аерым муниципаль мәгарифнең оешмалары җитәкчеләренең, аларның урынбасарларының хезмәт хакын билгеләү тәртибе

7.1. Аерым муниципаль белем бирү оешмалары җитәкчеләренең, аларның урынбасарларының хезмәт хакы вазифаи окладлардан, компенсация һәм кызыксындыру сыйфатындагы түләүләрдән гыйбарәт.

7.2. Аерым муниципаль белем бирү оешмалары җитәкчеләренең вазифаи оклады ($O_{\text{d}}$) гамәлгә куючы тарафыннан, агымдагы елның 1 сентябренә яки оешма оешу көненә, оешманың төренә һәм хезмәт өчен түләү төркеменә карап, елга бер тапкыр билгеләнә һәм түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$O_d = O_b \times \frac{H_{fk}}{H_N},$$

монда:

$O_b$ – җитәкченең төп оклад күләме;

$H_{fk}$ – аерым муниципаль белем бирү оешмасы җитәкчесе тарафыннан эшләнгән факттагы сәгатьләр саны;

$H_N$ – аерым муниципаль мәгариф оешмасы җитәкчесенең төп оклады өчен Россия Федерациясе Хезмәт кодексы нигезендә кабул ителә торган эш сәгатьләре нормасы.

7.3. Җитәкченең вазифаи оклады күләме 8 нче таблицада күрсәтелгән.

8 нче таблица

**Аерым муниципаль мәгариф оешмалары җитәкчеләре башкара торган эшләрнең сыйфаты өчен база окладлары һәм кызыксындыру характерындагы түләүләрнең күләме**

| **Оешманың исеме һәм төре** | **Төп оклад, сумнарда** | **Кызыксындыру характерындагы түләү, сумнарда** |
|---|---|---|
| Казан шәһәренең «Мәгариф хезмәткәрләре йорты» муниципаль бюджет учреждениесе | 28000,0 | 2000,0 |

7.4. Эшчәнлек үзенчәлекләре өчен кызыксындыру характерындагы өстәмә түләү ($B_{sop}$) гамәлгә куючы боерыгы нигезендә аерым муниципаль мәгариф оешмалары җитәкчеләренә бирелә һәм түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_{sop} = O_d \times \frac{D_{sop}}{100\%},$$

монда:

$O_d$ – аерым муниципаль мәгариф оешмалары җитәкчеләренең вазифаи оклады;

$D_{sop}$ – эшчәнлекнең үзенчәлеге өчен өстәмә түләү күләме.

Эшчәнлек үзенчәлеге өчен өстәмә түләү күләмнәре 9 нчы таблицада

китерелгән.

9 нчы таблица

**Эшчәнлек үзенчәлеге өчен түләү күләме**

| № т/б | Эшчәнлек үзенчәлеге өчен өстәмә түләү билгеләүнең нигезе | Һөнәри квалификация төркеме исеме | Квалифика-ция дәрәҗәсе | Өстәмә түләүләр күләме, процент-ларда |
|---|---|---|---|---|
| 1 | Казан шәһәренең «Мәгариф хезмәткәрләре йорты» муниципаль бюджет учреждениесендә эшләү | Җитәкче вазифасы | - | 100 |

7.5. Аерым муниципаль белем бирү оешмалары җитәкчеләре урынбасарларының вазифаи окладлары әлеге оешмалар җитәкчеләренең вазифаи окладларыннан 10-20 процентка түбәнрәк.

7.6. Казан шәһәре Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе аерым муниципаль белем бирү оешмалары җитәкчеләренә, эшчәнлекләре нәтиҗәләрен исәпкә алып, башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен кызыксындыру сыйфатындагы түләүләр билгели. Башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен кызыксындыру характерындагы түләүләр Казан шәһәре Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе әмере нигезендә билгеләнә. Сыйфат өчен кызыксындыру характерындагы түләүләр ай саен башкарыла.

Аерым муниципаль мәгариф оешмалары җитәкчеләренә кызыксындыру характерындагы түләүләр әлеге Нигезләмәнең 8 нче таблицасында китерелгән.

Аерым муниципаль белем бирү оешмалары җитәкчеләренә премия түләүләре рәвешендәге кызыксындыру характерындагы түләүләр ай саен, еллык эш нәтиҗәләре буенча квартал, ел өчен, мөһим һәм аеруча мөһим биремнәрне үтәү йомгаклары буенча бирелергә мөмкин. Җитәкчеләргә премия түләүләре Казан шәһәре Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе әмере нигезендә башкарыла.

Аерым муниципаль белем бирү оешмасы җитәкчесенең, җитәкче урынбасарларының финанс белән тәэмин итүнең барлык чыганаклары хисабына формалаша һәм календарь елга исәпләнә торган уртача айлык хезмәт хакының мондый оешмалар хезмәткәрләренең айлык уртача хезмәт хакына карата нисбәте (тиешле җитәкченең, аның урынбасарларының хезмәт хакын исәпкә алмыйча) өч тапкырдан артык була алмый.

7.7. Аерым муниципаль белем бирү оешмалары җитәкчеләре аерым муниципаль белем бирү оешмалары җитәкчеләре урынбасарларына, оешманың локаль норматив хокукый актлары белән гамәлгә кертелгән эшчәнлек нәтиҗәлелеге критерийлары нигезендә билгеләнгән эшчәнлек нәтиҗәләрен исәпкә алып, башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен кызыксындыру характерындагы түләүләр билгели. Җитәкче урынбасарларына кызыксындыру характерындагы түләүләр ай саен, квартал саен, еллык эш нәтиҗәләреннән чыгып, мөһим һәм аеруча мөһим биремнәрне үтәгән өчен бирелергә мөмкин. Җитәкче урынбасарлары өчен кызыксындыру характерындагы түләүнең чик дәрәҗәсе аерым муниципаль белем бирү оешмалары җитәкчеләренә кызыксындыру характерындагы түләүләрнең 70 проценты дәрәҗәсендә билгеләнә.

7.8. Башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен түләүләр түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_k = B_c \times K_{VK} ,$$

монда:

$B_k$ – башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен, аларның эшчәнлек нәтиҗәләрен исәпкә алып, кызыксындыру сыйфатындагы түләү;

$B_c$ – әлеге Нигезләмәнең 8 пунктында китерелгән кызыксындыру характерындагы түләүләр күләме;

$K_{VK}$ – сыйфат критерийларын үтәү коэффициенты.

7.9. Аерым муниципаль белем бирү оешмалары җитәкчеләре, җитәкче урынбасарлары өчен компенсация характерындагы түләүләр Россия Федерациясе Хезмәт кодексы нигезендә билгеләнә.

## VIII. Аерым муниципаль мәгариф оешмаларының хезмәте өчен түләү фондын булдыру тәртибе

8.1. Аерым муниципаль мәгариф оешмаларының хезмәте өчен түләү фондын формалаштыру норматив чыгымнарны, күрсәтелә торган хезмәтләрнең күләмнәрен исәпкә алып билгеләнгән агымдагы финанс елына акчалар күләме чикләрендә гамәлгә ашырыла һәм аерым муниципаль мәгариф оешмаларының финанс-хуҗалык эшчәнлеге планында чагыла.

8.2. Әлеге Нигезләмәдә билгеләнгән вазифаи окладларны, компенсация һәм кызыксындыру характерындагы түләүләрне исәпләү аерым муниципаль

мәгариф оешмалары хезмәткәрләренә (эшче, мәдәният эшчеләре, сәнгать һәм кинематографиянең гомумтармак һөнәрләре төркемнәре хезмәткәрләрен, җитәкчеләрнең, белгечләрнең һәм хезмәткәрләрнең гомумтармак вазифалары хезмәткәрләрен дә кертеп) хезмәт өчен түләүгә аерым муниципаль мәгариф оешмаларының финанс-хуҗалык эшчәнлеге планында агымдагы финанс елына каралган акчалар исәбеннән башкарыла.

8.3. Тиешле чор (ай, квартал, ел) өчен финанс белән тәэмин итүнең барлык чыганаклары, шул исәптән түләүле хезмәтләр күрсәтүдән алынган керемнәр хисабыннан аерым муниципаль мәгариф оешмаларының финанс-хуҗалык эшчәнлеге планын үтәү барышында барлыкка килгән хезмәт өчен түләү фондын экономияләү әлеге нигезләмә нормаларын исәпкә алып кабул ителгән аерым муниципаль мәгариф оешмаларының локаль норматив актлары нигезендә кызыксындыру түләүләренә җибәрелергә мөмкин.

Хезмәт өчен түләү фондын экономияләү булганда, бүләкләү түләүләре вазифаларның алар буенча хезмәт өчен түләү фонды экономияләнгән һөнәри квалификация төркеме хезмәткәрләренә бирелә (эшчеләр, мәдәният, сәнгать һәм кинематография эшчеләре гомумтармак һөнәрләренең һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләрен, җитәкчеләрнең, белгечләрнең һәм хезмәткәрләрнең гомумтармак вазифаларын да кертеп).

Хезмәт нормасын (хезмәт бурычларын) үтәгән аерым муниципаль мәгариф оешмалары хезмәткәренә (аерым муниципаль мәгариф оешмаларының педагогик хезмәткәрләре, җитәкчеләре вазифаларының һөнәри-квалификация төркеменә керүче хезмәткәрләрдән тыш) тиешле чорга, әлеге чорда үтәлгән эш вакыты нормасын исәпкә алып, хезмәт өчен түләү фондын экономияләү хисабыннан башкарылган кызыксындыру түләүләре күләме агымдагы елның 1 гыйнварына 2000 елның 19 июнендәге 82-ФЗ номерлы «Хезмәт өчен түләүнең минималь күләме турында»гы федераль законда билгеләнгән хезмәт өчен түләүнең минималь күләменнән өч тапкыр артык була алмый.

Финанс белән тәэмин итүнең барлык чыганаклары, шул исәптән түләүле хезмәтләр күрсәтүдән алынган керемнәр хисабыннан аерым муниципаль мәгариф оешмаларының финанс-хуҗалык эшчәнлеге планын үтәү барышында барлыкка килгән хезмәт өчен түләү фондын экономияләүдән файдалану өчен җаваплылык аерым муниципаль мәгариф оешмалары җитәкчесенә йөкләнә.

___________________

Казан шәһәре Башкарма комитетының
Мәгариф идарәсе карамагындагы
аерым оешмалар хезмәткәрләренең
хезмәте өчен түләү шартлары
турындагы нигезләмәгә
1 номерлы кушымта

**Мактаулы исемнәргә һәм ведомство бүләкләренә ия булган өчен аерым мәгариф оешмаларының мәгариф хезмәткәрләренә кызыксындыру характерындагы түләүләр бирелә торган мактаулы исемнәр һәм ведомство бүләкләре исемлеге**

| № т/б | Мактаулы исем, бүләк атамасы |
|---|---|
| Россия Федерациясенең, Татарстан Республикасының, Совет Социалистик Республикалар Союзының, Совет Социалистик Республикалар Союзы составындагы союздаш һәм автономияле республикаларның, Бәйсез Дәүләтләр Берлегенең мактаулы исемнәре | |
| 1. Россия Федерациясенең мактаулы исемнәре | |
| 1.1 | Россия Федерациясенең халык укытучысы |
| 1.2 | Россия Федерациясенең атказанган укытучысы |
| 1.3 | Россия Федерациясенең Атказанган фән эшлеклесе |
| 1.4 | Россия Федерациясенең атказанган югары мәктәп хезмәткәре |
| 1.5 | Россия Федерациясенең Атказанган җитештерү буенча белем бирү остасы |
| 1.6 | Россия Федерациясенең атказанган физик культура хезмәткәре |
| 1.7 | Россия Федерациясенең Атказанган мәдәният хезмәткәре |
| 1.8 | Россия Федерациясенең Атказанган рәссамы |
| 1.9 | Россия Федерациясенең Атказанган икътисадчысы |
| 2. Совет Социалистик Республикалар Союзының мактаулы исемнәре | |
| 2.1 | СССРның халык укытучысы |
| 3. Совет Социалистик Республикалары берлеге, Бәйсез Дәүләтләр берлеге составында союздаш республикаларның мактаулы исемнәре | |
| 3.1 | Атказанган физкультура һәм спорт эшлеклесе |
| 3.2 | Атказанган спорт эшлеклесе |
| 3.3 | Атказанган физик культура эшлеклесе |
| 3.4 | Атказанган физик культура һәм спорт хезмәткәре |

| №<br>т/б | **Мактаулы исем, бүләк атамасы** |
|---|---|
| 3.5 | РСФСРның атказанган тренеры |
| 3.6 | РСФСРның атказанган мәктәп укытучысы |
| 3.7 | Атказанган һөнәри-техник белем бирү укытучысы |
| 3.8 | Атказанган һөнәри-техник белем бирү остасы |
| 3.9 | Атказанган һөнәри-техник белем бирү хезмәткәре |
| 3.10 | Атказанган укытучы |
| 3.11 | Атказанган югары мәктәп хезмәткәре |
| 3.12 | Атказанган халык мәгарифе хезмәткәре |
| 3.13 | Атказанган югары мәктәп эшлеклесе |
| 3.14 | Атказанган фән һәм техника эшлеклесе |
| 3.15 | Атказанган фән эшлеклесе |
| 4. Совет Социалистик Республикалары берлеге, Бәйсез Дәүләтләр берлеге составындагы автономияле республикаларның мактаулы исемнәре | |
| 4.1 | Атказанган физкультура һәм спорт эшлеклесе |
| 4.2 | Атказанган физик культура һәм спорт хезмәткәре |
| 4.3 | Атказанган мәктәп эшлеклесе |
| 4.4 | Атказанган мәктәп укытучысы |
| 4.5 | Атказанган һөнәри-техник белем бирү укытучысы |
| 4.6 | Атказанган һөнәри-техник белем бирү остасы |
| 4.7 | Атказанган һөнәри-техник белем бирү хезмәткәре |
| 4.8 | Атказанган югары мәктәп хезмәткәре |
| 4.9 | Атказанган фән һәм мәдәният эшлеклесе |
| 4.10 | Атказанган мәдәният хезмәткәре |
| 4.11 | Атказанган фән һәм техника эшлеклесе |
| 4.12 | Атказанган фән эшлеклесе |
| 5. Татарстан Республикасының мактаулы исемнәре | |
| 5.1 | Татарстан Республикасының халык укытучысы |
| 5.2 | Татарстан Республикасының атказанган мәктәп укытучысы |
| 5.3 | Татарстан Республикасының атказанган укытучысы |
| 5.4 | Татарстан Республикасының Атказанган фән эшлеклесе |
| 5.5 | Татарстан Республикасының Атказанган югары мәктәп хезмәткәре |
| 5.6 | Татарстан Республикасының Атказанган физик культура хезмәткәре |
| 5.7 | Татарстан Республикасының Атказанган мәдәният хезмәткәре |
| 5.8 | Татарстан Республикасының Атказанган икътисадчысы |

| №<br>т/б | **Мактаулы исем, бүләк атамасы** |
|---|---|
| Кызыксындыру сыйфатындагы түләүләр бирелә торган Россия Федерациясенең, Татарстан Республикасының, Совет Социалистик Республикалар Союзының, Россия Совет Федератив Социалистик Республикасының ведомство бүләкләре | |
| 1. Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгы (Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгы) | |
| 1.1 | Россия Федерациясенең гомуми белем бирү мактаулы хезмәткәре |
| 1.2 | Россия Федерациясенең башлангыч һөнәри белем бирү мактаулы хезмәткәре |
| 1.3 | Россия Федерациясенең урта һөнәри белем бирү мактаулы хезмәткәре |
| 1.4 | Россия Федерациясенең югары һөнәри белем бирү мактаулы хезмәткәре |
| 1.5 | Россия Федерациясенең фән һәм техника мактаулы хезмәткәре |
| 1.6 | Россия Федерациясенең яшьләр сәясәте өлкәсе мактаулы хезмәткәре |
| 2. Халык мәгарифе министрлыгы,<br>СССРның (РСФСР) Мәгариф министрлыгы | |
| 2.1 | «СССРның мәгариф отличнигы» күкрәк билгесе |
| 2.2 | «Халык мәгарифе отличнигы» күкрәк билгесе |
| 2.3 | «СССРның һөнәри-техник белем отличнигы» күкрәк билгесе |
| 2.4 | «РСФСР һөнәри-техник белем отличнигы» күкрәк билгесе |
| 2.5 | «Россия Федерациясенең һөнәри-техник белем отличнигы» күкрәк билгесе |

Казан шәһәре Башкарма комитетының
Мәгариф идарәсе карамагындагы
аерым оешмалар хезмәткәрләренең
хезмәте өчен түләү шартлары
турындагы нигезләмәгә
2 номерлы кушымта

**Мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләренә кызыксындыру характерындагы түләүләр бирелә торган Россия Федерациясенең, Татарстан Республикасының, Совет Социалистик Республикалар Союзының, Совет Социалистик Республикалар Союзы составындагы союздаш һәм автономияле республикаларның мактаулы исемнәре исемлеге**

| № т/б | Мактаулы исем атамасы |
|---|---|
| 1. Россия Федерациясенең мактаулы исемнәре | |
| 1.1 | Россия Федерациясенең халык артисты |
| 1.2 | Россия Федерациясенең халык рәссамы |
| 1.3 | Россия Федерациясенең атказанган артисты |
| 1.4 | Россия Федерациясенең Атказанган мәдәният хезмәткәре |
| 1.5 | Россия Федерациясенең Атказанган рәссамы |
| 2. Татарстан Республикасының мактаулы исемнәре | |
| 2.1 | Татарстан Республикасының халык артисты |
| 2.2 | Татарстан Республикасының халык язучысы |
| 2.3 | Татарстан Республикасының халык шагыйре |
| 2.4 | Татарстан Республикасының халык рәссамы |
| 2.5 | Татарстан Республикасының атказанган артисты |
| 2.6 | Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе |
| 2.7 | Татарстан Республикасының Атказанган мәдәният хезмәткәре |
| 3. Совет Социалистик Республикалар Союзының мактаулы исемнәре | |
| 3.1 | СССРның халык артисты |
| 3.2 | СССРның халык рәссамы |
| 4. Совет Социалистик Республикалар Союзы составындагы союздаш республикаларның мактаулы исемнәре | |
| 4.1 | Атказанган пропагандачы |
| 4.2 | Халык артисты |

| №<br>т/б | Мактаулы исем атамасы |
|---|---|
| 4.3 | Атказанган артист |
| 4.4 | Атказанган сәнгать эшлеклесе |
| 4.5 | Халык рәссамы |
| 4.6 | Атказанган рәссам |
| 4.7 | Халык язучысы |
| 4.8 | Атказанган язучы |
| 4.9 | Халык шагыйре |
| 4.10 | Халык җырчысы |
| 4.11 | Халык акыны |
| 4.12 | Атказанган журналист |
| 4.13 | Атказанган мәдәният эшлеклесе |
| 4.14 | Атказанган мәдәни-мәгърифәтчелек эше хезмәткәре |
| 4.15 | Атказанган мәдәният хезмәткәре |
| 4.16 | Атказанган китапханәче |
| 4.17 | Гамәли сәнгать остасы |
| 4.18 | Атказанган халык иҗаты остасы |
| 4.19 | Атказанган фән эшлеклесе |
| 5. Совет Социалистик Республикалар Союзы составындагы автономияле республикаларның мактаулы исемнәре | |
| 5.1 | Атказанган төзүче |
| 5.2 | Халык артисты |
| 5.3 | Атказанган артист |
| 5.4 | Атказанган сәнгать эшлеклесе |
| 5.5 | Халык рәссамы |
| 5.6 | Атказанган рәссам |
| 5.7 | Халык язучысы |
| 5.8 | Атказанган язучы |
| 5.9 | Халык шагыйре |
| 5.10 | Атказанган журналист |
| 5.11 | Атказанган мәдәният хезмәткәре |
| 5.12 | Атказанган китапханәче |
| 5.13 | Атказанган фән һәм мәдәният эшлеклесе |
| 5.14 | Атказанган фән һәм техника эшлеклесе |
| 5.15 | Атказанган фән эшлеклесе |

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2024 елның 22 ноябрендәге
4789 номерлы карарына
2 номерлы кушымта

**Казан шәһәре Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе карамагындагы эшчеләр, мәдәният, сәнгать һәм кинематография эшчеләре гомумтармак һөнәрләренең, җитәкчеләр, белгечләр һәм хезмәткәрләр гомумтармак вазифаларының һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турында нигезләмә**

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Нигезләмә Казан шәһәре Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе карамагындагы аерым муниципаль оешмаларның эшче, мәдәният, сәнгать һәм кинематография эшче гомумтармак һөнәрләре, җитәкчеләр, белгечләр һәм хезмәткәрләр гомумтармак вазифалары һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең окладларын формалаштыру тәртибен, компенсация һәм кызыксындыру характерындагы түләү шартларын һәм күләмнәрен, шулай ук аларны билгеләү критерийларын билгели.

1.2. Әлеге Нигезләмәдә түбәндәге төшенчәләр һәм билгеләмәләр кулланыла:

- аерым муниципаль мәгариф оешмалары – Казан шәһәре Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе карамагындагы аерым муниципаль оешмалар: Казан шәһәренең «Мәгариф хезмәткәрләре йорты» муниципаль бюджет учреждениесе;

- хезмәткә түләү системасы – федераль законнар һәм Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары нигезендә билгеләнгән төп окладлар, хезмәт хакының төп ставкалары, вазифаи окладлар, шулай ук компенсация һәм кызыксындыру түләүләре күләмен дә кертеп, оешмалар хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартларын һәм күләмен билгели торган нормалар җыелмасы;

- төп оклад (вазифаи оклад, хезмәт хакы ставкасы) – аерым муниципаль мәгариф һәм мәдәният оешмаларының тиешле һөнәри квалификация төркеменә керә торган эшче яисә җитәкче, белгеч, техник башкаручы һөнәре буенча һөнәри эшчәнлек алып баручы хезмәткәрләренең минималь оклады, компенсация,

кызыксындыру һәм социаль түләүләрне исәпкә алмыйча;

- вазифаи оклад – кызыксындыру, компенсация характерындагы һәм социаль түләүләрне исәпкә алмыйча, бер календарь ай эчендә фактта эшләгән вакыт аралыгында билгеле бер катлаулылыктагы хезмәт (вазифаи) бурычларын үтәгән өчен хезмәткәрнең хезмәте өчен түләүнең билгеләнгән күләме;

- хезмәт хакы – хезмәткәрнең квалификациясенә, башкарыла торган эшнең катлаулылыгына, күләменә, сыйфатына һәм шартларына карап, хезмәт өчен түләү, шулай ук компенсация һәм кызыксындыру түләүләре;

- компенсация характерындагы түләүләр – компенсация характерындагы, шул исәптән нормага туры килмәгән шартларда эшләгән өчен өстәп һәм өстәмә түләүләр һәм компенсация характерындагы башка түләүләр;

- кызыксындыру характерындагы түләүләр – кызыксындыру характерындагы өстәп һәм өстәмә түләүләр, премияләр һәм башка кызыксындыру түләүләре.

1.3. Хезмәткәрнең хезмәт хакы (хезмәте өчен түләү) түбәндәгеләрдән чыгып билгеләнә:

- вазифаи оклад;
- компенсация характерындагы түләүләр;
- кызыксындыру сыйфатындагы түләүләрдән.

## II. Казан шәһәренең аерым муниципаль белем бирү оешмаларындагы эшчеләрнең, мәдәният, сәнгать һәм кинематография эшчеләренең гомумтармак һөнәрләре, җитәкчеләрнең, белгечләрнең һәм хезмәткәрләрнең гомумтармак вазифалары һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең төп окладларын билгеләү

2.1. Казан шәһәренең аерым муниципаль белем бирү оешмаларындагы эшчеләрнең, мәдәният, сәнгать һәм кинематография эшчеләренең гомумтармак һөнәрләре һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең төп окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| **Квалификация дәрәҗәсе** | **Бер айга төп оклад күләме, сумнарда** |
|---|---|
| «Беренче дәрәҗәдәге гомумтармак эшче һөнәрләре» һөнәри квалификация төркеме | |
| Беренче | 19242 |
| Икенче | 19440 |
| «Икенче дәрәҗәдәге гомумтармак эшче һөнәрләре» һөнәри квалификация төркеме | |
| Беренче | 19581 |

| Квалификация дәрәҗәсе | Бер айга төп оклад күләме, сумнарда |
| --- | --- |
| Икенче | 19755 |
| Өченче | 19933 |
| Дүртенче | 20464 |

2.2. Аерым муниципаль белем бирү оешмаларындагы җитәкчеләрнең, белгечләрнең һәм хезмәткәрләрнең гомумтармак вазифалары һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең төп окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Квалификация дәрәҗәсе | Бер айга төп оклад күләме, сумнарда |
| --- | --- |
| «Беренче дәрәҗәдәге гомумтармак хезмәткәрләр вазифалары» һөнәри квалификация төркеме | |
| Беренче | 19242 |
| Икенче | 19440 |
| «Икенче дәрәҗәдәге гомумтармак хезмәткәрләр вазифалары» һөнәри квалификация төркеме | |
| Беренче | 19581 |
| Икенче | 19755 |
| Өченче | 19933 |
| Дүртенче | 20160 |
| Бишенче | 20346 |
| «Өченче дәрәҗәдәге гомумтармак хезмәткәрләр вазифалары» һөнәри квалификация төркеме | |
| Беренче | 20536 |
| Икенче | 20729 |
| Өченче | 20926 |
| Дүртенче | 21127 |
| Бишенче | 21353 |
| «Дүртенче дәрәҗәдәге гомумтармак хезмәткәрләр вазифалары» һөнәри квалификация төркеме | |
| Беренче | 22265 |
| Икенче | 22465 |
| Өченче | 22665 |

2.3. Хезмәткәрнең вазифасы һәм һөнәре эшчеләрнең, мәдәният, сәнгать һәм кинематография эшчеләренең гомумтармак һөнәрләре, җитәкчеләрнең, белгечләрнең һәм хезмәткәрләрнең гомумтармак вазифалары һөнәри квалификация төркемнәренең квалификация дәрәҗәләренә туры килүе Россия

Федерациясе Сәламәтлек саклау һәм социаль үсеш министрлыгының норматив хокукый актлары нигезендә кабул ителә.

2.4. Берьюлы ике эштә, шулай ук тулы булмаган эш вакыты шартларында эшләүче хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләү эшләнгән вакытка пропорциональ рәвештә яки башкарылган эш күләменнән чыгып гамәлгә ашырыла. Төп вазифа буенча, шулай ук икенче вазифа буенча хезмәт хакы күләмнәре һәр вазифа буенча аерым билгеләнә.

## III. Казан шәһәренең аерым муниципаль белем бирү оешмаларындагы эшчеләрнең, мәдәният, сәнгать һәм кинематография эшчеләренең гомумтармак һөнәрләре, җитәкчеләрнең, белгечләрнең һәм хезмәткәрләрнең гомумтармак вазифалары һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең вазифаи окладларын билгеләү тәртибе

Аерым муниципаль белем бирү оешмаларындагы гомумтармак һөнәрләре хезмәткәрләренең, мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләренең, гомумтармак җитәкчеләр, белгечләр һәм хезмәткәрләр вазифаларының һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең төп окладлары ($O_{\text{d}}$) түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$O_d = O \times \frac{H_f}{H_N},$$

монда:

$H_f$ – аерым муниципаль мәгариф оешмалары хезмәткәренең хезмәткәрләр өчен билгеләнгән эш вакыты озынлыгы чикләрендәге факттагы эш сәгатьләре саны;

$H_N$ – гомумтармак һөнәрләре хезмәткәрләренең, мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләренең, гомумтармак җитәкчеләр, белгечләр һәм хезмәткәрләр вазифаларының төп оклады өчен Россия Федерациясе Хезмәт кодексы нигезендә кабул ителә торган сәгать нормасы;

О – әлеге Нигезләмәнең II бүлеге нигезендә кабул ителә торган аерым муниципаль мәгариф оешмалары гомумтармак һөнәрләре хезмәткәрләренең, мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләренең, гомумтармак җитәкче, белгеч һәм хезмәткәр вазифаларының һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең төп оклады күләме.

## IV. Кызыксындыру характерындагы түләүләр

4.1. Кызыксындыру характерындагы түләүләргә хезмәткәрне сыйфатлы хезмәт нәтиҗәсенә кызыксындыруга, шулай ук башкарган эш өчен бүләкләүгә юнәлдерелгән түләүләр керә.

4.2. Кызыксындыру сыйфатындагы түләүләр түбәндәгеләрне үз эченә ала:

- дәүләт бүләкләренә ия булган өчен түләүләр;
- вазифа буенча эш стажы өчен түләүләр;
- премия һәм башка кызыксындыру түләүләре;

4.3. Мактаулы исемнәр булган өчен түләүләр ($B_{pz}$) гомумтармак һөнәрләре хезмәткәрләренең, мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләренең, гомумтармак җитәкче, белгеч һәм хезмәткәр вазифаларының һөнәри квалификация төркемнәренә кергән хезмәткәрләренә түләнә һәм түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_{pz} = O_d \times \frac{D_{pz}}{100\%},$$

монда:

$O_d$ – аерым муниципаль мәгариф оешмаларындагы эшчеләр, мәдәният, сәнгать һәм кинематография эшчеләре гомумтармак һөнәрләре, җитәкче, белгеч һәм хезмәткәр гомумтармак вазифаларының һөнәри квалификация төркемнәренә кергән хезмәткәрләренең вазифаи окладлары;

$D_{pz}$ – мактаулы исемнәргә ия булган өчен өстәмә түләү күләме өч процент тәшкил итә.

4.3.1. Хезмәткәрләргә мактаулы исемнәргә һәм бүләкләргә ия булган өчен тиешле түләүләр бирелә торган мактаулы исемнәр һәм бүләкләр исемлеге әлеге Нигезләмәнең кушымтасында китерелгән.

4.3.2. Мактаулы исемгә, дәүләт бүләгенә ия булган өчен түләү күләмнәрен билгеләү мактаулы исем, дәүләт бүләге бирелгән көннән башкарыла. Ике һәм аннан да күбрәк мактаулы исемнәргә һәм (яки) ике һәм аннан да күбрәк дәүләт бүләкләренә ия булган хезмәткәрләргә түләү хезмәткәр сайлаган нигезләрнең берсе буенча билгеләнә.

4.4. Җитәкче, белгеч һәм хезмәткәр гомумтармак вазифаларының һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренә вазифа (белгечлек) буенча эш стажы өчен түләүләр ($B_s$) вазифасы (белгечлеге) буенча эш дәвамлылыгына бәйле рәвештә һөнәри квалификация төркемнәре һәм квалификация дәрәҗәләренең төркемнәре буенча стажга карап билгеләнә һәм түбәндәге формула белән исәпләнә:

$$B_s = O_d \times \frac{D_s}{100\%},$$

монда:

$O_d$ – аерым муниципаль мәгариф оешмаларының җитәкче, белгеч һәм хезмәткәр гомумтармак вазифаларының һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең вазифаи оклады;

$D_s$ – вазифасы (белгечлеге) буенча эш стажы өчен өстәмә түләү күләме.

4.4.1. Вазифа (белгечлек) буенча эш стажы өчен өстәмә түләү күләме түбәндәгечә билгеләнә:

- вазифа (белгечлек) буенча эш стажы 2 дән 5 елга кадәр булганда – 2,5 процент;
- вазифа (белгечлек) буенча эш стажы 5 тән 10 елга кадәр булганда – 4 процент;
- вазифа (белгечлек) буенча эш стажы 10 нан 15 елга кадәр булганда – 5 процент;
- вазифа (белгечлек) буенча эш стажы 15 елдан артык булганда – 6 процент.

4.4.2. Эш стажы үзгәргәндә вазифа (белгечлек) буенча эш стажы өчен түләүләр күләме, әгәр стажны раслый торган документлар оешмада булса, эш стажы өчен түләүләр күләмен арттыру хокукын бирә торган стажны тутырган көннән алып, яки стажны раслый торган кирәкле документ бирелгән көннән алып билгеләнә (үзгәртелә).

4.4.3. Вазифа (белгечлек) буенча эш стажына, таблица нигезендә, вазифалар (һөнәрләр) буенча эш вакыты кертелә.

Таблица

**Әлеге вазифаларда эшләгән вакыт вазифа (белгечлек) буенча эш стажына кертелә торган вазифалар (һөнәрләр) исемлеге**

| № т/б | Җитәкчеләр, белгечләр һәм хезмәткәрләр гомумтармак вазифаларының һөнәри квалификация төркемнәре («баш», «өлкән» дигән вазифаи атамаларны да кертеп, барлык вазифа эчендәге категорияләр) хезмәткәрләре вазифалары атамалары | Кызыксындыру түләвен билгеләү өчен эшләү вакыты аралыгы белгечлек буенча эш стажына кертелә торган вазифалар (һөнәрләр) атамасы |
|---|---|---|
| 1 | Финанс бүлеге башлыгы, план-икътисад бүлеге башлыгы, баш бухгалтер урынбасары, бухгалтер, бухгалтер-ревизор, икътисадчы, бухгалтерлык хисабы һәм хуҗалык эшчәнлеге анализы буенча икътисадчы, исәпләү (мәгълүмат-исәп) үзәге икътисадчысы, шартнамә һәм претензия эше буенча икътисадчы, финанс эше буенча икътисадчы, планлаштыру буенча техник, хисапчы, калькулятор, кассир, таксировщик, статистик, исәпкә алучы | Финанс бүлеге башлыгы, план-икътисад бүлеге башлыгы, баш бухгалтер урынбасары, бухгалтер, бухгалтер-ревизор, икътисадчы, бухгалтерлык хисабы һәм хуҗалык эшчәнлеге анализы буенча икътисадчы, исәпләү (мәгълүмат-исәп) үзәге икътисадчысы, шартнамә һәм претензия эше буенча икътисадчы, матди-техник тәэминат буенча икътисадчы, планлаштыру буенча икътисадчы, сату буенча икътисадчы, хезмәт буенча икътисадчы, финанс эше буенча икътисадчы, планлаштыру буенча икътисадчы, хисапчы, калькулятор, кассир, таксировщик, статистик, исәпкә алучы, салымнар һәм җыемнар буенча консультант, аудитор |
| 2 | Матди-техник яктан тәэмин итү буенча икътисадчы | Матди-техник тәэмин итү буенча икътисадчы, матди-техник тәэмин итү бүлеге башлыгы, склад мөдире, бухгалтер, бухгалтер-ревизор, икътисадчы, бухгалтерлык хисабы һәм хуҗалык эшчәнлеге анализы буенча икътисадчы, хисаплау (мәгълүмат-хисап) үзәге икътисадчысы, килешү һәм претензия эше буенча икътисадчы, планлаштыру буенча икътисадчы, сату буенча икътисадчы, финанс эше буенча икътисадчы, товар белгече, планлаштыру буенча техник, хисапчы, таксировщик, исәпкә алучы |
| 3 | Оештыру һәм хезмәт өчен түләү бүлеге башлыгы | Хезмәтне оештыру һәм түләү бүлеге башлыгы, хезмәтне оештыру һәм җитештерү белән идарә итү лабораториясе (бюросы) башлыгы, хезмәт буенча норматив-тикшеренү лабораториясе башлыгы, хезмәт социологиясе лабораториясе (бюросы) башлыгы, социаль үсеш бүлеге |

| № т/б | Җитәкчеләр, белгечләр һәм хезмәткәрләр гомумтармак вазифаларының һөнәри квалификация төркемнәре («баш», «өлкән» дигән вазифаи атамаларны да кертеп, барлык вазифа эчендәге категорияләр) хезмәткәрләре вазифалары атамалары | Кызыксындыру түләвен билгеләү өчен эшләү вакыты аралыгы белгечлек буенча эш стажына кертелә торган вазифалар (һөнәрләр) атамасы |
|---|---|---|
| | | башлыгы, хезмәт буенча икътисадчы, хезмәтне нормалаштыру буенча инженер, хезмәтне оештыру һәм нормалаштыру буенча инженер, хезмәтне оештыру буенча инженер, инструктор-дактилолог, хезмәт буенча техник, социолог, нарядчы, хронометражист |
| 4 | Хезмәтне саклау бүлеге башлыгы, хезмәтне саклау һәм куркынычсызлык техникасы буенча инженер | Хезмәтне саклау бүлеге башлыгы, хезмәтне оештыру һәм түләү бүлеге башлыгы, хезмәтне оештыру һәм җитештерү белән идарә итү буенча лаборатория (бюро) башлыгы, хезмәт буенча норматив-тикшеренү лабораториясе башлыгы, хезмәтне саклау һәм куркынычсызлык техникасы инженеры, инженер |
| 5 | Кадрлар бүлеге (махсус бүлек һ.б.) башлыгы, кадрлар әзерләү бүлеге башлыгы, персонал буенча менеджер, кадрлар буенча белгеч, кадрлар буенча инспектор, кадрлар әзерләү буенча инженер | Кадрлар бүлеге (махсус бүлек һәм башкалар) башлыгы, кадрлар әзерләү бүлеге башлыгы, персонал буенча менеджер, кадрлар буенча белгеч, кадрлар буенча инспектор, кадрлар әзерләү буенча инженер, инструктор-дактилолог, профконсультант, юрисконсульт, табельче |
| 6 | Социаль үсеш бүлеге башлыгы | Социаль үсеш бүлеге башлыгы, кадрлар бүлеге башлыгы, кадрлар әзерләү бүлеге башлыгы, хезмәтне оештыру һәм түләү бүлеге башлыгы, хезмәтне оештыру һәм җитештерү белән идарә итү лабораториясе (бюро) башлыгы, хезмәт социологиясе лабораториясе (бюросы) башлыгы, хезмәтне саклау бүлеге башлыгы, персонал буенча инженер, кадрлар буенча белгеч, инструктор-дактилолог, кадрлар буенча инспектор, хезмәтне саклау һәм куркынычсызлык техникасы инженеры, хезмәтне нормалаштыру буенча инженер, хезмәтне оештыру һәм нормалаштыру буенча инженер, хезмәтне |

| № т/б | Җитәкчеләр, белгечләр һәм хезмәткәрләр гомумтармак вазифаларының һөнәри квалификация төркемнәре («баш», «өлкән» дигән вазифаи атамаларны да кертеп, барлык вазифа эчендәге категорияләр) хезмәткәрләре вазифалары атамалары | Кызыксындыру түләвен билгеләү өчен эшләү вакыты аралыгы белгечлек буенча эш стажына кертелә торган вазифалар (һөнәрләр) атамасы |
|---|---|---|
| | | оештыру буенча инженер, хезмәт буенча техник, социолог |
| 7 | Профконсультант | Профконсультант, кадрлар бүлеге башлыгы, кадрлар буенча белгеч, кадрлар буенча инспектор, персонал буенча менеджер, психолог, социолог, халыкны эш белән тәэмин итү үзәге инспекторы, инструктор-дактилолог |
| 8 | Юридик бүлек башлыгы, юрисконсульт | Юридик бүлек башлыгы, юрисконсульт |
| 9 | Архив мөдире, канцелярия мөдире, документовед, архивариус, эш башкаручы, йөкләмәләр үтәлешен контрольдә тоту буенча инспектор, секретарь, секретарь-машинистка, секретарь-стенографистка, күрмәүче белгеч секретаре, җитәкче секретаре, экспедитор | Архив мөдире, канцелярия мөдире, документовед, архивариус, эш башкаручы, йөкләмәләр үтәлешен контрольдә тоту инспекторы, секретарь, секретарь-машинистка, секретарь-стенографистка, стенографистка, машинистка, күрмәүче белгеч секретаре, җитәкче секретаре, паспортчы, кодификатор, экспедитор |
| 10 | Машинкада бастыру бюросы мөдире, күчермәләр-нөсхәләр ясау бюросы мөдире, машинистка | Машинкада бастыру бюросы мөдире, күчермәләр-нөсхәләр ясау бюросы мөдире, машинкада бастыручы, машинкада бастыручы сәркатип, күчермәләр ясаучы белгеч |
| 11 | Матди-техник тәэмин итү бүлеге башлыгы, хуҗалык бүлеге башлыгы, склад мөдире, хуҗалык мөдире | Матди-техник тәэмин итү бүлеге башлыгы, хуҗалык бүлеге башлыгы, склад мөдире, хуҗалык мөдире, товар белгече, агент, сатып алулар агенты, тәэмин итү буенча агент, тәэмин итү буенча икътисадчы, товар белгече, йөкләр ташу буенча экспедитор |
| 12 | Тулай торак мөдире, пропусклар бюросы дежуры, комендант, администратор | Пансионатның (кунакханәнең) торак корпусы мөдире, тулай торак мөдире, пропусклар бюросы мөдире, ял бүлмәсе мөдире, хуҗалык мөдире, пропусклар бюросы дежуры, белешмәләр бирү, |

| № т/б | Җитәкчеләр, белгечләр һәм хезмәткәрләр гомумтармак вазифаларының һөнәри квалификация төркемнәре («баш», «өлкән» дигән вазифаи атамаларны да кертеп, барлык вазифа эчендәге категорияләр) хезмәткәрләре вазифалары атамалары | Кызыксындыру түләвен билгеләү өчен эшләү вакыты аралыгы белгечлек буенча эш стажына кертелә торган вазифалар (һөнәрләр) атамасы |
|---|---|---|
| | | кунакханә залы, автомобиль йөртүчеләрнең ял итү бүлмәсе, тулай торак һәм башкалар буенча дежур, комендант, администратор, саклау камерасы мөдир |
| 13 | Гараж башлыгы | Гараж башлыгы, автоколонна башлыгы, пассажир транспорты контролеры, диспетчерлык хәрәкәте һәм төяү-бушату эшләре операторы, автотехник экспертиза буенча белгеч (эксперт-автотехник), юл хуҗалыгы эксперты, автотранспорт йөртүчесе |
| 14 | Җитештерү мөдире (шеф-пешекче), ашханә мөдире | Җитештерү мөдире (шеф-пешекче), ашханә мөдире, пешекче |
| 15 | Диспетчер, диспетчерлык хезмәте операторы | Диспетчер, диспетчерлык хезмәте операторы, диспетчерлык хәрәкәте һәм төяү-бушату эшләре операторы |
| 16 | Фотолаборатория мөдире | Фотолаборатория мөдире, фотограф, рәссам-фотограф |
| 17 | Механик, ремонт буенча инженер, инженер-энергетик (энергетик) | Ремонт цехы башлыгы, остаханә башлыгы (мөдире), механик, ремонт буенча инженер, инженер-энергетик (энергетик), инженер |
| 18 | Инженер-программачы (программачы), техник-программачы, математик, фонд инспекторы, фонд инспекторы ассистенты | Җитештерү белән идарә итүнең автоматлаштырылган системасы бүлеге башлыгы, җитештерү процессларын автоматлаштыру һәм механикалаштыру бүлеге башлыгы, инженер-программачы (программачы), җитештерү процессларын автоматлаштыру һәм механикалаштыру буенча инженер, җитештерү белән идарә итүнең автоматлаштырылган системалары буенча инженер, инженер, математик, техник-программист, техник, фонд инспекторы, фонд инспекторы ассистенты |
| 19 | Фәнни-техник китапханә мөдире, мәгълүмат бүлеге | Фәнни-техник китапханә мөдире, мәгълүмат бүлеге башлыгы, фәнни-техник мәгълүмат бүлеге |

| № т/б | Җитәкчеләр, белгечләр һәм хезмәткәрләр гомумтармак вазифаларының һөнәри квалификация төркемнәре («баш», «өлкән» дигән вазифаи атамаларны да кертеп, барлык вазифа эчендәге категорияләр) хезмәткәрләре вазифалары атамалары | Кызыксындыру түләвен билгеләү өчен эшләү вакыты аралыгы белгечлек буенча эш стажына кертелә торган вазифалар (һөнәрләр) атамасы |
|---|---|---|
| | башлыгы, мәгълүматны саклау бүлеге (лаборатория, сектор) башлыгы, фәнни-техник мәгълүмат буенча инженер, мәгълүматны саклау буенча инженер, мәгълүматны саклау буенча белгеч, мәгълүматны саклау буенча техник | башлыгы, мәгълүматны саклау бүлеге (лаборатория, сектор) башлыгы, фәнни-техник мәгълүмат буенча инженер, мәгълүматны саклау буенча инженер, патент һәм уйлап табу эше буенча инженер, инженер, мәгълүматны саклау буенча белгеч, мәгълүматны саклау буенча техник, техник |
| 20 | Техник-икътисади тикшеренүләр лабораториясе (бюросы) башлыгы, тикшеренү лабораториясе башлыгы, мәгълүмат бүлеге башлыгы, аналитик | Техник-икътисади тикшеренүләр лабораториясе (бюросы) башлыгы, тикшеренү лабораториясе башлыгы, мәгълүмат бүлеге башлыгы, фәнни-техник мәгълүмат бүлеге башлыгы, аналитик |
| 21 | Инженер-лаборант, техник-лаборант, лаборант | Заводның үзәк лабораториясе башлыгы, җитештерү лабораториясе (җитештерүне контрольдә тоту буенча) башлыгы, инженер-лаборант, инженер, техник-лаборант, техник, лаборант |
| 22 | Инструмент буенча техник, техник-технолог | Җитештерү бүлеге башлыгы, техник бүлек башлыгы, сынаулы җитештерү цехы башлыгы, инструменталь бүлек башлыгы, җитештерү процессларын автоматлаштыру һәм механикалаштыру бүлеге башлыгы, җиһазларны туплау бүлеге башлыгы, цех (участок) башлыгы, (участок, цех) контроль остасы, участок остасы, инженер, җитештерүне әзерләү буенча инженер, инженер-технолог, җитештерү процессларын автоматлаштыру һәм механикалаштыру буенча инженер, инструмент буенча инженер, җиһазларны туплау буенча инженер, инженер-конструктор, җитештерү белән идарә итүне оештыру буенча инженер, патент һәм уйлап табу |

| № т/б | Җитәкчеләр, белгечләр һәм хезмәткәрләр гомумтармак вазифаларының һөнәри квалификация төркемнәре («баш», «өлкән» дигән вазифаи атамаларны да кертеп, барлык вазифа эчендәге категорияләр) хезмәткәрләре вазифалары атамалары | Кызыксындыру түләвен билгеләү өчен эшләү вакыты аралыгы белгечлек буенча эш стажына кертелә торган вазифалар (һөнәрләр) атамасы |
|---|---|---|
| | | эше буенча инженер, фәнни-техник мәгълүмат буенча инженер, механик, техник, техник-конструктор, инструмент буенча техник, техник-технолог |
| 23 | Инженер | Барлык атамадагы инженер, җитештерү бүлеге башлыгы, техник бүлек башлыгы, сынаулы җитештерү цехы башлыгы, җитештерү процессларын автоматлаштыру һәм механикалаштыру бүлеге башлыгы, цех (участок) башлыгы, капиталь төзелеш бүлеге башлыгы, участок остасы, механик, техник, техник-конструктор, инструмент буенча техник, техник-технолог |
| 24 | Инженер-электроник (электроник), исәпләү (мәгълүмат-исәп) үзәге техникы | Инженер-электроник (электроник), исәпләү (мәгълүмат-хисап) үзәге техникы, инженер, инженер-программист (программист), техник-программачы, техник |
| 25 | Күчермә ясаучы | Сызымчы, сызымчы-конструктор, күчермәләр ясаучы, рәссам |
| 26 | Психолог | Психолог, медицина психологы, педагог-психолог, профконсультант |
| 27 | Физиолог | Физиолог, биолог |
| 28 | Социолог | Социолог, хезмәт социологиясе лабораториясе (бюросы) башлыгы |
| 29 | Рәссам | Барлык атамалардагы рәссамнар, архитектор, сызымчы |
| 30 | Архитектор | Рәссам-конструктор (дизайнер), сызымчы-конструктор, сызымчы |
| 31 | Тәрҗемәче-дактилолог, сурдотәрҗемәче | Тәрҗемәче-дактилолог, сурдотәрҗемәче |
| 32 | Бүлек (ферма, авыл хуҗалыгы участогы) белән идарә итүче | Бүлек (ферма, авыл хуҗалыгы участогы) белән идарә итүче, агроном, зоотехник |
| 33 | Башка аерымланган структур | Тиешле төрдәге икътисади эшчәнлек |

| № т/б | Җитәкчеләр, белгечләр һәм хезмәткәрләр гомумтармак вазифаларының һөнәри квалификация төркемнәре («баш», «өлкән» дигән вазифаи атамаларны да кертеп, барлык вазифа эчендәге категорияләр) хезмәткәрләре вазифалары атамалары | Кызыксындыру түләвен билгеләү өчен эшләү вакыты аралыгы белгечлек буенча эш стажына кертелә торган вазифалар (һөнәрләр) атамасы |
|---|---|---|
| | бүлекчә филиалы директоры (башлыгы, мөдире) | хезмәткәрләре вазифаларының һөнәри квалификация төркемнәренә кертелгән вазифалар |

4.5. Хезмәткәрләргә премия һәм башка бүләкләү түләүләре билгеле бер вакыт аралыгы (ай, квартал, ел) өчен, шулай ук юбилей даталары, аерым хөрмәт билгеләре, рәхмәт хатлары, грамоталар, бүләкләр алуга бәйле рәвештә берьюлы һәм оешманың локаль актларында һәм коллектив килешүләрендә күрсәтелгән башка нигезләрдә билгеләнә.

4.5.1. Премияләр һәм башка кызыксындыру түләүләрен башкару күләме, тәртибе һәм шартлары аерым муниципаль мәгариф оешмаларының локаль норматив хокукый актлары һәм коллектив килешүләр белән билгеләнә.

4.5.2. Эшчеләрнең, культура, сәнгать һәм кинематографиягә караган гомумтармак эшче һөнәрләре хезмәткәрләренең һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренә, җитәкчеләрнең, белгечләрнең һәм хезмәткәрләрнең гомумтармак вазифаларына премия түләүләренә каралган хезмәт өчен түләү фондының тәкъдим ителә торган күләме төп вазифа һәм төп эш урыны буенча хезмәткәрләргә окладларны (вазифаи окладларны) түләүгә, кызыксындыру характерындагы башка түләүләргә каралган хезмәт өчен түләү фондының кимендә ике процентын тәшкил итә.

## V. Компенсация сыйфатындагы түләүләр

5.1. Компенсация характерындагы түләүләргә түбәндәгеләр керә:

- зарарлы һәм (яисә) куркыныч хезмәт шартлары булган эшләрдә эшләүче хезмәткәрләргә түләүләр;
- нормаль шартлардан тайпылган шартларда (төрле квалификация эшләрен башкарганда, һөнәрләрне (вазифаларны) берләштергәндә, эш сәгатеннән тыш эшләгән өчен, төнлә эшләгән һәм нормаль шартлардан тайпылган башка шартларда эшләр башкарганда) эшләгән өчен түләүләр.

5.2. Зарарлы һәм (яисә) куркыныч хезмәт шартлары булган эшләрдә һәм нормага туры килмәгән шартларда эшләгән (берничә һөнәрне (вазифаны) берьюлы башкару, эш сәгатеннән тыш эшләү, төнлә эшләү, хезмәт күрсәтү зоналарын киңәйтү, эш күләме арту яки хезмәт килешүе белән билгеләнгән эштән азат ителмәгән килеш вакытлыча эштән азат ителгән хезмәткәр вазифаларын үтәү, ял көннәрендә һәм эш көне булмаган бәйрәм көннәрендә эшләү) өчен хезмәткәрләргә компенсация сыйфатындагы түләүләр законнар нигезендә һәм аерым муниципаль мәгариф оешмаларының тиешле финанс елына расланган хезмәт өчен түләү фонды чикләрендә билгеләнә.

Компенсация сыйфатындагы түләүләр, аларны гамәлгә ашыру күләмнәре һәм шартлары хезмәт законнары һәм хезмәт хокукы нормалары булган башка норматив хокукый актлар нигезендә күмәк шартнамәләр, килешүләр, локаль норматив актлар, әлеге Нигезләмә белән билгеләнә.

Зарарлы һәм (яисә) куркыныч хезмәт шартлары булган эшләрдә эшләүче хезмәткәрләргә компенсация характерындагы түләүләр ($B_{kh}$) түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_{kh} = O \times \frac{D_{kh}}{100\%} \times \frac{H_{fk}}{H_N},$$

монда:

O – аерым муниципаль мәгариф оешмаларындагы эшче, мәдәният, сәнгать һәм кинематография эшчеләре гомумтармак һөнәрләре, җитәкче, белгеч һәм хезмәткәр гомумтармак вазифаларының һөнәри квалификация төркемнәренә кергән хезмәткәрләренең төп окладлары;

$D_{kh}$ – Россия Федерациясе Хезмәт кодексы нигезендә кабул ителә торган компенсация характерындагы өстәмә түләү күләме;

$H_{fk}$ – законнар белән компенсация характерындагы түләүләр карала торган факт буенча эшләнгән вакыт;

$H_N$ – гомумтармак һөнәрләре хезмәткәрләренең, мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләренең, гомумтармак җитәкче, белгеч һәм хезмәткәр вазифаларының төп оклады өчен Россия Федерациясе Хезмәт кодексы нигезендә кабул ителә торган сәгать нормасы.

Зарарлы һәм (яисә) куркыныч хезмәт шартлары булган эшләрдә эшләүче хезмәткәрләрнең хезмәтенә түләү нормаль хезмәт шартларында төрле эшләр өчен билгеләнгән окладлар (вазифаи окладлар) белән чагыштырганда күбрәк

күләмдә, хезмәт шартларын махсус бәяләү нигезендә кимендә дүрт процент күләмендә билгеләнә.

5.3. Нормага туры килмәгән шартларда эшләгән өчен компенсация характерындагы түләүләр Россия Федерациясе Хезмәт кодексы нигезендә билгеләнә.

Һөнәрләрне (вазифаларны) берләштергәндә, хезмәт күрсәтү зоналарын киңәйткәндә, эш күләмен арттырганда яки хезмәт килешүендә билгеләнгән эштән азат ителмәгән килеш эштән вакытлыча азат ителгән хезмәткәр вазифаларын үтәгәндә, өстәмә эшнең эчтәлеген һәм (яки) күләмен исәпкә алып, хезмәт килешүен төзегән вәкилләрнең килешүе буенча билгеләнә торган күләмдә хезмәткәргә өстәмә түләнә.

Казан шәһәре Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе карамагындагы эшче, мәдәният, сәнгать һәм кинематография эшчеләре гомумтармак һөнәрләренең, җитәкче, белгеч һәм хезмәткәр гомумтармак вазифаларының һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турында нигезләмәгә кушымта

**Кызыксындыру сыйфатындагы түләүләр бирелә торган Россия Федерациясенең, Татарстан Республикасының, Совет Социалистик Республикалар Союзының, Социалистик Республикалар Союзы составындагы союздаш һәм автономияле республикаларның дәүләт бүләкләре исемлеге**

| № т/б | Мактаулы исем, бүләк атамасы |
|---|---|
| 1. Россия Федерациясенең мактаулы исемнәре | |
| 1.1 | Россия Федерациясенең халык рәссамы |
| 1.2 | Россия Федерациясенең Атказанган архитекторы |
| 1.3 | Россия Федерациясенең Атказанган сәнгать эшлеклесе |
| 1.4 | Россия Федерациясенең Атказанган фән эшлеклесе |
| 1.5 | Россия Федерациясенең Атказанган җир төзүчесе |
| 1.6 | Россия Федерациясенең Атказанган зоотехнигы |
| 1.7 | Россия Федерациясенең Атказанган уйлап табучысы |
| 1.8 | Россия Федерациясенең Атказанган конструкторы |
| 1.9 | Россия Федерациясенең Атказанган җитештерү буенча белем бирү остасы |
| 1.10 | Россия Федерациясенең Атказанган машина төзүчесе |
| 1.11 | Россия Федерациясенең Атказанган халыкка көнкүреш хезмәте күрсәтү хезмәткәре |
| 1.12 | Россия Федерациясенең Атказанган торак-коммуналь хуҗалык хезмәткәре |
| 1.13 | Россия Федерациясенең Атказанган азык-төлек индустриясе хезмәткәре |

| №<br>т/б | Мактаулы исем, бүләк атамасы |
|---|---|
| 1.14 | Россия Федерациясенең Атказанган элемтә хезмәткәре |
| 1.15 | Россия Федерациясенең Атказанган текстиль һәм җиңел сәнәгать хезмәткәре |
| 1.16 | Россия Федерациясенең Атказанган транспорт хезмәткәре |
| 1.17 | Россия Федерациясенең Атказанган рационализаторы |
| 1.18 | Россия Федерациясенең Атказанган эчке эшләр органнары хезмәткәре |
| 1.19 | Россия Федерациясенең Атказанган коткаручысы |
| 1.20 | Россия Федерациясенең Атказанган төзүчесе |
| 1.21 | Россия Федерациясенең Атказанган рәссамы |
| 1.22 | Россия Федерациясенең Атказанган икътисадчысы |
| 1.23 | Россия Федерациясенең Атказанган энергетигы |
| 1.24 | Россия Федерациясенең Атказанган юристы |
| 2. Татарстан Республикасының мактаулы исемнәре, дәүләт бүләкләре | |
| 2.1 | Татарстан Республикасының халык рәссамы |
| 2.2 | Татарстан Республикасының Атказанган архитекторы |
| 2.3 | Татарстан Республикасының Атказанган фән эшлеклесе |
| 2.4 | Татарстан Республикасының Атказанган уйлап табучысы |
| 2.5 | Татарстан Республикасының Атказанган машина төзүчесе |
| 2.6 | Татарстан Республикасының Атказанган торак-коммуналь хуҗалык хезмәткәре |
| 2.7 | Татарстан Республикасының Атказанган җиңел сәнәгать хезмәткәре |
| 2.8 | Татарстан Республикасының Атказанган азык-төлек сәнәгате хезмәткәре |
| 2.9 | Татарстан Республикасының Атказанган элемтә хезмәткәре |
| 2.10 | Татарстан Республикасының Атказанган транспорт хезмәткәре |
| 2.11 | Татарстан Республикасының Атказанган рационализаторы |
| 2.12 | Татарстан Республикасының Атказанган эчке эшләр органнары хезмәткәре |
| 2.13 | Татарстан Республикасының Атказанган коткаручысы |
| 2.14 | Татарстан Республикасының Атказанган төзүчесе |
| 2.15 | Татарстан Республикасының Атказанган икътисадчысы |
| 2.16 | Татарстан Республикасының Атказанган энергетигы |
| 2.17 | Татарстан Республикасының Атказанган юристы |
| 3. Совет Социалистик Республикалар Союзының мактаулы исемнәре | |

| № т/б | Мактаулы исем, бүләк атамасы |
|---|---|
| 3.1 | СССРның халык архитекторы |
| 3.2 | СССРның атказанган уйлап табучысы |
| 3.3 | СССРның атказанган сәнәгать хезмәткәре |
| 3.4 | СССРның атказанган төзүчесе |
| 3.5 | СССРның атказанган транспорт хезмәткәре |
| 3.6 | СССРның атказанган элемтә хезмәткәре |
| 3.7 | СССР Кораллы Көчләренең атказанган белгече |
| 4. Совет Социалистик Республикалар Союзы составындагы союздаш республикаларның мактаулы исемнәре | |
| 4.1 | Атказанган сәнәгать хезмәткәре |
| 4.2 | Атказанган энергетик |
| 4.3 | Атказанган машина төзүче |
| 4.4 | Атказанган азык-төлек индустриясе хезмәткәре |
| 4.5 | Атказанган полиграфист |
| 4.6 | Атказанган транспорт хезмәткәре |
| 4.7 | Атказанган автотранспорт хезмәткәре |
| 4.8 | Атказанган элемтәче |
| 4.9 | Атказанган элемтә хезмәткәре |
| 4.10 | Атказанган төзүче |
| 4.11 | Атказанган халыкка көнкүреш хезмәте күрсәтү хезмәткәре |
| 4.12 | Атказанган көнкүреш хезмәте хезмәткәре |
| 4.13 | Атказанган коммуналь хуҗалык хезмәткәре |
| 4.14 | Атказанган торак-коммуналь хуҗалык хезмәткәре |
| 4.15 | Атказанган халыкка коммуналь һәм көнкүреш хезмәте күрсәтү хезмәткәре |
| 4.16 | Атказанган коммуналь-көнкүреш хезмәте хезмәткәре |
| 4.17 | Атказанган социаль тәэмин итү хезмәткәре |
| 4.18 | Атказанган фән һәм техника эшлеклесе |
| 4.19 | Атказанган фән эшлеклесе |
| 4.20 | Атказанган юрист |
| 4.21 | Атказанган инженер |
| 4.22 | Атказанган уйлап табучы |
| 4.23 | Атказанган рационализатор |
| 4.24 | Атказанган оста |

| №<br>т/б | Мактаулы исем, бүләк атамасы |
|---|---|
| 4.25 | Атказанган икътисадчы |
| 4.26 | Атказанган бухгалтер |
| 4.27 | Атказанган (эшләүче, эшче) яшьләр остазы |
| 5. Совет Социалистик Республикалар союзы составындагы автономияле республикаларның мактаулы исемнәре | |
| 5.1 | Атказанган сәнәгать хезмәткәре |
| 5.2 | Атказанган машина төзүче |
| 5.3 | Атказанган медицина сәнәгате хезмәткәре |
| 5.4 | Атказанган транспорт хезмәткәре |
| 5.5 | Атказанган шофер |
| 5.6 | Атказанган машина йөртүче |
| 5.7 | Атказанган элемтәче |
| 5.8 | Атказанган элемтә хезмәткәре |
| 5.9 | Атказанган төзүче |
| 5.10 | Атказанган сәүдә һәм җәмәгать туклануы хезмәткәре |
| 5.11 | Атказанган сәүдә хезмәткәре |
| 5.12 | Атказанган халыкка көнкүреш хезмәте күрсәтү хезмәткәре |
| 5.13 | Атказанган көнкүреш хезмәте хезмәткәре |
| 5.14 | Атказанган торак-коммуналь хуҗалык хезмәткәре |
| 5.15 | Атказанган фән һәм мәдәният эшлеклесе |
| 5.16 | Атказанган фән һәм техника эшлеклесе |
| 5.17 | Атказанган фән эшлеклесе |
| 5.18 | Атказанган юрист |
| 5.19 | Атказанган милиция хезмәткәре |
| 5.20 | Атказанган техник |
| 5.21 | Атказанган инженер |
| 5.22 | Атказанган уйлап табучы |
| 5.23 | Атказанган рационализатор |
| 5.24 | Атказанган икътисадчы |
| 5.25 | Атказанган бухгалтер |
| 5.26 | Атказанган халык хуҗалыгы хезмәткәре |
| 5.27 | Атказанган рационализатор һәм уйлап табучы |